# ИСЛАМ ДИНЕ ЙОЛАЛАРЫ

Казан

ШУРАЛАР ЖУМҺУРИЯТЕ ЕВРОПА БҮЛЕГЕ ҺӘМ СЕБЕР МӨСЕЛМАННАРЫНЫҢ ДИНИЯ НӘЗАРАТЫ.

# ИСЛАМ ДИНЕ ЙОЛАЛАРЫ

(тәһәрәт, гөсел, намаз уку, намаз вакытлары, мәет күмү, никах, балага исем кушу, Иман, аның мәгънәсе һәм башкалар).

Казан, 1990 ел.

Басма өчен җаваплы Казан Әҗем мәчете
мөтәвәллиәт раисе Һади Әхмәтвәлиев

Китапны басарга әзерләделәр һәм гәрәпчә текстларны тәҗвид кагидәсе белән күчерделәр Әҗем мәчетенең мөтәвәллиәт әгзалары:

Разия Сибгатулла кызы ЗАКИРОВА,
Фәридә Мөхәммәтгариф кызы ХӘСӘНОВА.

Басманың эчтәлеген вә тәҗвид кагидәсенең дөреслеген
ДУМЕС әгзасы — Чистай шәһәренең имам хатибе
Габделхак әфәнде Саматов тикшерде.

Ислам дине йолаларын үтәүнең нигезләрен аңлаткан бу китап СССРның Европа бүлеге һәм Себер мөселманнарының Диния нәзараты рөхсәте буенча чыгарыла.

ӘГҮҮЗӨ БИЛӘӘҺИ МИНӘШШӘЙТААНИРРАЖИИМ
БИСМИЛЛӘӘҺИРРАХМӘӘНИРРАХИИМ

## ГИЛЕМ ХАКЫНДА

РАББИ ЗИДЕНИ ГИЛМӘН НӘФИГӘН МӨГӘММИЛӘН ГАФИЛӘН.

Мәгънәсе: И, Раббем! Миңа хәерле гилем бир, гафил итмә.

Әмин.

## АЛЛАҺЫ ТӘГАЛӘ

Аллаһы тәгаләне белмәк — һәрбер бәндәгә фарыздыр, ләкин Аның затыны белергә безнең гакылымызның куәте житмидер. Безләргә аны сыйфатлары илә генә белмәк мөмкиндер. Аллаһә тәгаләнең күркәм сыйфатлары бик күптер.

## КОРЪӘН НӘРСӘ УЛ?

Аллаһө сөбөхәнә вә тәгаләдән пәйгәмбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһө гәләйһисәлләмгә Җәбраил фирештә аркылы, яшерен аваз белән иңдерелмеш гәзиз китаптыр. Коръәндәге сүзләр һәрберсе Аллаһы тәгалә сүзләредер.

Динебез ислам булып, пәйгәмбәребез ахыр заман пәйгәмбәредер. Аллаһы тәгалә тарафыннан пәйгәмбәребезгә Җәбраил фирештә аркылы 23 ел буе аят-аят иңдерелмеш китабыбыз Коръәнел кәримдер. Ул Коръән кәримнең индерелмеш сүзләрен дөрес итеп, тәҗвид белән укымак һәркайсыбызга фарыз вә лаземдер. Аллаһы тәгалә Коръән кәримне пәйгәмбәребезгә тәҗвид илә индерде. Хөрмәтле Коръән кәримне ялгыш укымак олуг гөнаһдыр. Коръәнне дөрес укыган кеше дөньяда да, әхыйраттә дә бәхетле кешедер. Яшь булса да, карт булса да Коръәнне тырышып, тәҗвид илә укырга өйрәнмәк фарыз булыр. Һәркем Коръәнне ихласы илә тәҗвид белә укыса, һәр хәрефенә ун савап вә дәрәҗә булыр.

Әмин.

---

ИСКӘРМӘ: ЛӘӘ, ЛӘӘӘӘ, ЛАА дип язылган сүзләрне ЛӘ Ә, ЛӘ Ә Ә Ә, ЛА А дип укырга түгел, ә бәлки музыкаль алым белән бер тоташтан сузып укырга кирәк, ә дип бер мәртәбә әйткәч туктап тормыйча гына язылган хәрефләрне укып бетергәнче сузып торырга кирәк.

# ИСЛАМ

Ислам — Аллаһы тэгаләдән килгән хак дин буенча гэмәл кылу димәктер. Аллаһы тәгаләдән Мөхәммәд гәләйһиссәламгә килгән дин — Ислам дине дип аталадыр. Ислам диненең хаклыгына ышанган кеше мө'мин вә мөселман дип аталыр.

Ислам дине пак диндер, пак булырга тырышыгыз. Пак булмаган кеше җәннәткә кермәс.

Ислам дине паклек өстенә төзелмешдер. Динебез ислам дине — бик хак вә бик пак бер диндер. Мөселман кешенең күңеле яман холыклардан вә явыз фигыльләрдән; тәне: киеме, йорты-җире һәм ашы-суы һәрбер нәҗесләрдән пак булмак тиешледер. Хосүсән, намаз укыганда вә башка гибәдәтләрне кыйлганда мөселман кеше бигрәк тә пак булырга тиеш.

Аллаһының барлыгына, берлегенә ышанып, үлеп-терелүгә, кыямәт көненә һәм андагы булачак хәлләргә ышангач, ЛӘӘӘӘ ИЛӘӘҺӘ ИЛЛӘЛЛААҺӨ МӨХӘММӘДӨРРАСҮҮЛҮЛЛААҺИ дип әйтергә кирәк.

Мәгънәсе: гибәдәт кыйлырга, ярдәм сорарга, сыгынырга яраклы башка затлар юктыр, мәгәр бер Аллаһө тәгалә генәдер, Мөхәммәд Мостафа салләллаһө гәләйһиссәләм Аллаһө тәгаләнең дин хөкемен өйрәтеп, гәмәлдә эшләп күрсәтүчедер.

Аллаһө тәгаләгә ышануның беренче дәлиле, өстә әйтелгәнчә, иман китерү булса, икенче дәлиле биш вакыт намаз уку.

Бу биш вакыт намаз Аллаһының әмре. Җир йөзендәге нигмәтләргә шөкерана кыйлып яшәвебез шул намаз белән генә табыла.

Намаз укучы булмасак җир йөзендә буш ашаучы, буш яшәүче булабыз.

Мөселман кешенең өченче бурычы Рамазан аенда елына бер ай ураза тоту белән була, монысы тәннең зәкяте була.

Мөселман кешенең дүртенче бурычы: маллары зәкятка житсә, малының кырыктан бер өлешен ятим-фәкирләргә бирергә тиешледер.

Мөселманның бишенче бурычы: хәле (мал-мөлкәте) житсә гөмерендә бер мәртәбә ХАҖ кылу белән була. Болар барсыда Аллаһө тәгаләнең катгый боерыкларыдыр.

**Әгүүзөбиллләәһи минәшшәйтааниррәҗиимның мәгънәсе**

ӘГҮЗӨ [1] — сыгынамын.

Кемнән сыгынасың?

БИЛЛӘӘҺИ — бөтен галәмне һәм анда булган һәрбер затларны юктан бар кыйлучым Аллаһө тәгаләгә.

Нәрсәдән сыгынасың?

МИНӘШШӘЙТААНИРРАҖИИМ — Аллаһы тәгаләнең рәхмәтеннән сөрелмеш шәйтанның зарарыннан сыгынамын.

Шәйтан — Иблис ни өчен Аллаһы тәгаләнең рәхмәтеннән сөрелде?

Аллаһы тәгалә безнең бабабыз Әдам галәйһисәлләмне балчыктан яраткач, фәрештәләргә аны олылыклап сәҗдә кылырга кушты. Фәрештәләр сәҗдә кылдылар, Иблис: «Мин уттан ярат‌ылган зат, Әдам балчыктан яратылды, ут балчыктан югарырак,— дип, Аллаһының боерыгын үтәмәде, сәҗдә кылмады, тәкәбберләнде. Бер мәртәбә сәҗдә кылмаганы өчен мәңгелеккә хур булып, Аллаһы хозурыннан сөрелде.

Асыл гибәдәтебез нәрсә соң?

Асыл гибәдәтебез — вакытында торгызылган намазларыбыз. Моннан аңлашыла ки: без гибәдәт кылган вакытта безне шәйтан вәсвәсәсеннән (котыртуыннан) сакла дигән сүз.

БИСМИЛЛӘӘҺИРРАХМӘӘНИРРАХИИМ

гиззәтле булган Аллаһы тәгаләнең шәриф булган исме белән бу изге эшемне башлыймын.

Бисмилләһиррахмәниррахим дигән сүзне хәрам эш эшләгәндә әйтү тыела, гөнаһ була.

## ПАКЛАНУ

Бәдрәфкә кергәндә әүвәл сул аякны атлап керү, чыкканда әүвәл уң аякны атлап чыгу тиешдер.

Бәдрәфтә кечкенә вә олуг хәҗәтен кылган кеше сул кулы белән истинҗә кылу, ягни яхшылап юып, коры чүпрәк белән сөртергә кирәк. Истинҗәне уң кул белән, печән вә кәгаз кеби кәдерле нәрсәләр белән кылу мәкруһдыр (гөнаһтыр).

---

[1] Өсләренә бу билге куелган хәрефләр аз гына сакау укылалар.

## ТӘҺӘРАТ.

Дөреслектә тәһәратләнү иманның яртысыдыр, дөреслектә ул тәһәрат намазның ачкычыдыр вә дәхи тәнне паклаучыдыр.

«Сезнең берегез коенса олугы ага торган елгадан көненә биш мәртәбә, калырмы ул кешенең тәнендә кер?»— диде Мөхәммәд Мостафа салләллаһу гәләйһисәлләм. «Юк, һич калмас»— диделәр сахәбәләр.

Тәһәратне бер тоташтан алып бетерергә кирәк, тәһәрат алганда дөнья сүзен сөйләшмәк гөнаһ була.

### Тәһәратнең мөстәхәбләре 3 дер.

1. Тәһәрат алганда кыйблага каршы тормак.
2. Су чәчрәмәслек биек җирдә тормак.
3. Суны үзе хәзерләмәк.

### Тәһәрат алу тәртибе.

1. Эчке тәһәрат алырга (хаҗәтен үтәгәч су белән юып, чиста чүпрәк илә сөртмәк).

2. Кулларны өч мәртәбә юарга (эчке тәһәраттән соң сабын белән кул юу тәһәраткә керми).

3. Авызга өч мәртәбә су алып чайкарга.

4. Уң кул белән өч мәртәбә борынга су аласың, сул кул белән сеңгерәсең.

5. Битеңә су аласың өч мәртәбә (маңгай чәчләреннән алып, колак яфракларыннан алып, ияк асларына кадәр).

6. Элек ике беләгеңә дә су чылатып, башта уң беләгеңә терсәктән бер кул яссы югары 3 мәртәбә су аласың, аннан нәкъ шулай сул беләгенә өч мәртәбә су аласың.

7. Башыңның дүрттән бер өлешенә мәсих тартасың: элек чәнчә бармагыңнан өч бармак илә ике кулың белән чәч юлыннан җилкә чокырына кадәр төшәсең, аннан дүртенче бармагың илә колак эченә кереп, астан югарыга таба өч урынга мәсих кыласың, баш бармакларың илә колак артыннан өскә таба килеп, маңгай уртасына кадәр ике яклап килеп тоташасың.

Ике кулыңның кул аркасы белән муеннан ияк астына кадәр мәсих кыласың.

8. Аякларны юганда: тубыктан алып, уң аякның чәнчә

бармагыннан алып баш бармагына кадәр, бармак араларына кереп су тидерәсе, ә сул аякның баш бармагыннан алып чәнчә бармакка кадәр араларына су кертеп юасың.

Тәһәратне алып бетергәч Әшһәдә әл лә иләһә иллаллаһу вә әшһәдү әннә Мөхәммәдәр расулуллаһ дип битеңне сөртәсең.

Әмин.

## ГӨСЕЛ

Гөселне фарыз иткән нәрсәләр:

1. Җөнеб гөселе (ир белән хатын якынлык кыйлгач).

2. Нифас гөселе (40 көн бала тапканнан соң, 41 нче көннән башлана).

3. Хәез гөселе (хатын-кызның күрем вакыты беткәннән соң, ул 3 көннән 7 көнгә кадәр дәвам итәргә мөмкин).

БУ ГӨСЕЛЛӘР МӘҖБҮРИ.

4. Ихтиярый гөселләр: төшләнсәң, төрле чагында. Шулай ук гәед, җомга гөселләре.

## ГӨСЕЛ ТӘРТИБЕ

1. Әүвәл авызга су алмак — тамак төбен гаргара кылып 3 мәртәбә чайкарга.

2. Борынга су алмак 3 мәртәбә.

3. Бөтен әгзаларга су тидермәк, коры җирең калмаслык итеп.

Намаз укыган вакытта намаз укыган урының, намазлыгың, өс-башың чиста булырга тиеш.

Кояш чыгып торган вакытта, кояш баткан вакытта намаз уку дөрес булмас.

Намазны кыйблага карап уку фарыздыр. Кыйбланың кай тарафта икәнен белә торып, башка тарафка карап уку һичтә дөрес булмас.

Намаз укып торган вакытта кыйбланың икенче тарафта икәнен сизенсә, намазын бозмаенча шул тарафка әйләнер.

Намазлык өстенә баскач кул баглаганда сул кулының беләзеген уң кулының баш вә чәнчә бармаклары белән чорнап алып, урта бармакларын беләгенә таба сузу тиешледер.

Намазда укылган сүрә зекерләрне тәҗвид илә бик дөрес итеп уку тиешледер.

Намаз ахырында сәләм биргәндә арттагы кешегә яцагың күренерлек кадәр башны бору тиештер.

Кыямда (аяк үрә торганда) сәждә урынына гына, рикогда (ярым бөгелгәндә) аяк башларына гына, сәждәдә борынына гына, кәгдәдә (утырганда) үз алдына гына, сәләм биргәндә иң башларына гына карап тору тиешледер.

Намаз эчендә түбәнчелек кыяфәт вә сынык күңел белән тору тиеш.

Кыямда торганда (аяк үрә торганда) укчәләре бер-берсеннән дүрт бармак киңлеге аерылып торыр.

Сәждәдә вакытта кул вә аяк бармаклары кыйблага таба сузылып торыр.

Рокугда вакытта (бөгелгәндә) ирләрнең кул бармаклары тезләренә таянып торган вакытта һәммәсе ачык булыр, хатыннарныкы ачык булмас.

Намаз эчендә йөткермәскә вә иснәмәскә тырышыгыз. Ихтиярсыз иснәгәндә авызны бер кул илә капламак кирәк.

Тәһәраткә кысталган вакытта намаз уку дөрес булмас.

БИСМИЛЛӘӘҺИРРАХМӘЭНИРРАХИИМ

## НАМАЗ

Намаз димәк Аллаһы тәгаләгә мәглүм рәвештә күңел вә тән белән гибәдәт кылу димәктер. Һәрбер мөъмин бәндәгә тәүлек эчендә биш вакыт намаз уку фарыз булыр: иртә намазы, өйлә, икенде, ахшам, ястү (ясигы) намазлары.

## НАМАЗ ВАКЫТЛАРЫ.

ИРТӘНГЕ НАМАЗ: Кояш чыкканчы сәгат ярым алдан, таң вакыты кергәч.

2 рикәгат сөннәт укыла
2 рикәгат фарыз укыла

ӨЙЛӘ НАМАЗЫ: Төш вакыты (зәүәл) авышып 10—15 минут үткәч, икенде вакыты кергәнче.

4 рикәгат сөннәт
4 рикәгат фарыз
2 рикәгат сөннәт

ИКЕНДЕ НАМАЗЫ: Кояш баерга ике сәгат алдан, ко-

яш баеганчы (озын көннәрдә, барасы җирең булса — 3 сәгат алдан укырга ярый).
4 рикәгат фарыз укыла.

АХШАМ НАМАЗЫ: Кояш баегачта шәфәк кызыллыгы беткәнче.
3 рикәгат фарыз
2 рикәгат сөннәт.

ЯСИГЫ (ястү) намазы: Кояш батып бер сәгат, сәгат ярым үткәч, таң вакыты кергәнче.
4 рикәгат фарыз
2 рикәгат сөннәт
3 рикәгат ВИТР ВӘҖЕП намазы.

## НАМАЗ НИЯТЛӘҮ:

Намазлыкка баскач әгүзе-бисмилләне әйтеп өч мәртәбә: әстәгфируллаһә — тәүбә вә әтүбө иләйһи дип әйтәбез дә, намаз ниятлибез:

1. Иләһи ният кылдым, иртәнге намазымның ике рикәгат сөннәтен үтәмәккә, юнәлдем кыйбла тарафына: ХАЛИСӘН ЛИЛЛӘҺИ ТӘГАЛӘ, АЛЛААҺӨ ӘКБӘР дип кулларыңны иң өстенә күтәрәсең.

2. Кулларыңны күкрәгенә куеп:

1. СӨБӨХӘӘНӘКӘ
2. ӘЛХӘМ
3. ИННӘӘ ӘГТАЙНӘНЕ

укыйсың да Аллаһө әкбәр дип рокугга барасың, ягни ярым бөгеләсең. Рокугда (ярым бөгелгәндә) кулларыңны тезләренә куясың да, өч мәртәбә СӨБӨХӘӘНӘ РАББИӘЛ ГӘЗЫЙМ дип әйтәсең. СӘМИГАЛЛААҺӨ ЛИМӘН ХӘМИДӘҺ дигән сүзне әйтә-әйтә рокугыдан торасың. Аннары «Раббәнә ләкәл хәмдө» диясең. Аллааһө әкбәр дип сәҗдәгә китәсең. Сәҗдәдә өч мәртәбә СӨБӨХӘӘНӘ РАББИӘЛ ӘГЛӘӘ дип әйтәсең дә, Аллааһө әкбәр дип торып утырасың, аз гына утырып алгач кабат сәҗдәгә китәсең, сәҗдәдә кабат өч мәртәбә СӨБӨХӘӘНӘ РАББИӘЛ ӘГЛӘӘ дип әйтәсең, Аллааһө әкбәр дип торып басасың.

Боларны үтәп бетергәч бер рикәгат намазыбыз тәмам була.

2 нче рикәгатне үтәгәндә:

Аллааһө әкбәр дип сәждәдән торып баскач, кулыңны күкрәгеңә куеп, бисмилләне әйтеп:

1. Әлхәм
2. Ҡольһүаллаһө

укып рокугга барасың, рокугда өч мәртәбә СӨБӨХӘӘНӘ РАББИӘЛ ГӘЗЫЙМ дип әйтәсең. СӘМИГАЛЛААҺУ ЛИМӘН ХӘМИДӘҺ РАББӘНӘӘ ЛӘҠӘЛ ХӘМДӨ Аллаһө әкбәр дип сәждәгә китәсең, сәждәдә өч мәртәбә СӨБӨХӘӘНӘ РАББИӘЛ ӘГЛӘ дип әйтәсең дә Аллааһө әкбәр дип утырасың, аз гына утырып алгач кабат Аллааһө әкбәр дип сәждәгә китәсең, сәждәдә өч мәртәбә СӨБӨХӘӘНӘ РАББИӘЛ ӘГЛӘ дип әйтәсең дә, Аллааһө әкбәр дип утырасың, әттәхийят укыйбыз. Бөтен әттәхийят укып бетергәч, раббәнә сүрәсен укып, Әссәләәмө гәләйкөм вә рахмәтуллааһ дип әүвәл үң якка, аннан сул якка Әссәләәмө гәләйкөм вә рахмәтуллааһ дип сәлам бирәбез.

Сәләм биргәннән соң кулларыбызны күтәреп өч мәртәбә әстәгъфируллаһә дип әйтеп. АЛЛААҺӨММӘ ӘНТӘССӘЛӘМӨ ВӘ МИНКӘССӘЛӘМӨ дип дога кылабыз.

Шушыларны үтәп бетергәч безнең иртәнге намазыбызның 2 рикәгат сөннәт намазы үтәлгән була.

Иртәнге намазның ике рикәгат сөннәтен укып бетергәч, 2 рикәгат фарыз намазы укыла.

Фарыз намазы да сөннәт намазы кебек укыла.

Намазны укып бетергәч аннан соң укыласы догаларны укып, намазыбызны багышлыйбыз.

**Иртәнге намаз**

## СӨННӘТ.

1 нче рикәгаттә: Сөбөхәнәкә, Әлхәм, Иннә әгтайнә укыла.

2 нче рикәгаттә: Әлхәм, Ҡольһүаллаһ укыла.

Укып бетергәч бөтен әттәхийят укыла.

## ФАРЫЗ.

1 нче рикәгаттә: Сөбөхәнәкә, Әлхәм, Иннә әгтайнә укыла.

2 нче рикәгаттә: Әлхәм, Кольһуаллаһ укыла.

Укып бетергәч бөтен эттәхийят укыла.

**Өйлә намазы**

### 4 рикәгат сөннәт.

1 нче рикәгаттә Сөбеханәкә, Әлхәм, Иннә әгтайнә укыла.

2 нче рикәгаттә: Әлхәм, Кольһуаллаһ укыла.

Шуннан соң ярты эттәхийят укыйбыз да яңадан торып басабыз,

3 нче рикәгаттә Әлхәм, Кольһуаллаһ укыла.

4 нче рикәгаттә Әлхәм, Кольһуаллаһ укыла.

Укып бетергәч бөтен эттәхийят укыла.

(теләге булган кеше Кольһуаллаһө урынына башка сүрә яки аятләрне куша ала. Мәсәлән: вәлгасри, иннәәә әнзәлнәһө вә башкалар).

### 4 рикәгат фарыз.

1 нче рикәгаттә Сөбөханәкә, Әлхәм, Иннә әгтайнә укыла.

2 нче рикәгаттә: Әлхәм, Кольһуаллаһ укыла.

Шуннан соң ярты эттәхийят укыйбыз да, яңадан торып басабыз.

3 нче рикәгаттә Әлхәм укыла.

4 нче рикәгаттә Әлхәм укыла.

Болардан соң бөтен эттәхийят укыла.

### 2 рикәгат сөннәт.

1 нче рикәгаттә Сөбөханәкә, Әлхәм, Иннә әгтайнә укыла.

2 нче рикәгаттә: Әлхәм, Кольһуаллаһ укыла.

Бөтен эттәхийят укыйбыз.

Шушының белән өйлә намазы тәмам.

### Икенде намазы — 4 рикәгат фарыз.

1 нче рикәгаттә Сөбөханәкә, Әлхәм, Иннә әгтайнә укыла.

2 нче рикәгаттә: Әлхәм, Кольһуаллаһ укыла.

Ярты эттэхийят укыйбыз да, яңадан торып басабыз.

3 нче вә 4 нче рикәгатләрдә берәр мәртәбә Әлхәм укыла.

Бөтен Әттәхийят укыйбыз.

**Ахшам намазы.**

**3 рикәгат фарыз.**

1 нче рикәгаттә Сөбхәнәкә, Әлхәм, Иннә әгтайнә укыла.

2 нче рикәгаттә: Әлхәм, Кольһуаллаһ укыла.

Ярты Әттәхийят укыйбыз.

3 нче рикәгаттә Әлхәм укыла.

Бөтен Әттәхийят укыйбыз.

**2 рикәгат сөннәт.**

1 нче рикәгаттә Сөбхәнәкә, Әлхәм, Иннә әгтайнә укыла.

2 нче рикәгаттә: Әлхәм, Кольһуаллаһ укыла.

Бөтен Әттәхийят укыйбыз.

**Ясигы (ястү) намазы.**

**4 рикәгат фарыз.**

1 нче рикәгаттә Сөбхәнәкә, Әлхәм, Иннә әгтайнә укыйбыз.

2 нче рикәгаттә: Әлхәм, Кольһуаллаһ укыла.

Ярты Әттәхийят укыйбыз.

3 нче рикәгаттә Әлхәм укыла.

4 нче рикәгаттә дә Әлхәм укыла.

Бөтен Әттәхийят укыйбыз.

**2 рикәгат сөннәт.**

1 нче рикәгаттә Сөбхәнәкә, Әлхәм, Иннә әгтайнә укыла.

2 нче рикәгаттә: Әлхәм, Кольһуаллаһ укыла.

Бөтен Әттәхийят укыйбыз.

**3 рикәгат витр вәҗеб намазы.**

1 нче рикәгаттә Сөбехәнәкә, Әлхәм, Иннә әгтайнә укыла.

2 нче рикәгаттә: Әлхәм, кольһуалла укыла.

Ярты Әттәхийят укыйбыз.

3 нче рикәгаттә Әлхәм, кольһуалланы укып, күкрәк өстенә баглаган кулларыбызны кире төшереп, яңадан Аллаһө әкбәр дип иң өстенә күтәрәбез дә, яңадан күкрәгебезгә баглаб кнут догасын укыйбыз, аны өйрәнгәнче һәр кайсында бисмиллә беләп башлап өч мәртәбә раббәнәне укыйбыз да сәждәгә китеп, калганын башка намазлар кебек тәмамлыйбыз.

Бөтен Әттәхийят укыйбыз.

Намаз тәмам булганнан соң Сөбөхәналлаһи, Аятөлкөрси укып тәсбих тартасың, тәсбих догасы укып дога кыласың.

Намаздан соң берәр сүрә яки аят укып әрвахларга дога кыласың, аларны багышлап:

«Я, Раббем! Укыган сүрә вә аятләремне үзеңнең ризалыгың өчен, пәйгәмбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһө гәләйһиссәләмнең рухи шәрифләренә, атабыз Әдам гәләйһиссәләм, анабыз Хава разиаллаһы гәнһәнең вә башка пәйгәмбәрләрнең, барча изгеләрнең, барча сәхабәләрнең, остазларыбызның, әти-әниләребезнең, әби-бабаларыбызның, барча ир һәм кыз туганнарыбызның, вафат булган хәләл җефетләребезнең, вафат булган ир һәм кыз балаларыбызның, бездән дога өмет иткән җәмиге әрвахларыбызның рух-шәрифләренә ирештерсәң иде»,— дип дога кыласың.

Биш вакыт намазның беренче 2 рикәгате бөтен намазда да иртәнге ике рикәгат сөннәт намазы кеби укыла.

Әлхәм сүрәсе намаз эчендә һәрвакыт бисмилләһи әйтеп укыла. Башка сүрәләрдә бисмилләһи әйтелми.

## НАМАЗ ЭЧЕНДӘ УКЫЙ ТОРГАН ДОГАЛАР.

СӨБӨХӘӘНӘКӘ— ошбу дога **СӘНӘ** дип атала.

Сөбөхәәнәкә әллааһөммә вә бихәмдикә вә тәбәракәс-мүкә вә тәгәлә җәддөкә вә ләәәә иләәһә гайрок.

### ӘЛХӘМ — фәтихә сүрәсе.

Әлхәмдө лилләһи раббил гәәләмиин. Әррахмәнирраxиим. Мәлики йәүмиддин. Иййәәкә нәгбөдө вә иййәәкә нәстәгин. Иһдинәссыйраатаaль мөстәкыыйм. Сыйрааталләзинә әнгәмтә гәләйһим, гайрил мәгдүүби гәләйһим вәләддаааaллиин.

Әмин.

### Иннә эгтайнә.

Иннәәәә эгтайнәәкәл кәүсәр. Фәсалли лираббикә вәнхәр. Иннәә шәәни әкә һөвәл әбөтәр.

### ҠОЛЬҺҮАЛЛАҺӨ Ихлас сүрәсе

Ҡольһүаллаһө әхәдө. Аллааһөссамәдө. Ләм йәлидө вә ләм йүләде вә ләм йәкөлләһү көфөвән әхәдө.

## ӘТТӘХИЙЙӘТ — ТӘШӘҺҺӨД

Әттәхиййәтө лилләәһи вәссаләвәәтө вәттайиибәәтө, әссәләәмө гәләйкә әййөһәннәбиййө вә рахмәтуллааһи вә бәракәәтөһү әссәләәмө гәләйнәә вәгәләә гәбәәдилләәһиссалихиин, әшһәдө әл ләәәә иләәһә илләәллааһө вә әшһәдө әннә Мөхәммәдән гәбәдөһү вә расулөһө.

бу ярты эттәхиййәт була.

### Салават.

Аллаһөммә салли гәлә мөхәммәдин вәгәләәәә әәли Мөхәммәд. Ҡәмәә салләйтә гәләәәә Ибраһиимә вәгәләәәә әәли Ибраһиимә иннәкә хәмиидөм мәҗиде. Аллааһөммә бәәрик гәләәәә Мөхәммәдин вәгәләәәә әәли Мөхәммәд. Ҡәмәә бәәрактә гәләәәә Ибраһиимә вәгәләәәә әәли Ибраһиимә иннәкә хәмиидөм мәҗиидө.

Моны укыгач бөтен эттәхиййәт була.

## ТӘСБИХ ТАРТУ ТӘРТИБЕ.

Намазны укып бетәрәк ике якка сәләм биргәч:

Сөбөхәәналлааһи вәлхәмдө лилләәһи вә ләәәә иләәһә илләллааһө вәллааһө әкбәр. Ләәхәүлә вәләә куүвәтә иллә билләәһил гәлиййил гәзыйм. Мәәшәәәәъ Әллааһө кәәнә вәмәә ләм йәшәъ ләм йәкөн дибез дә, Аятөлкөрси укыйбыз.

## АЯТӨЛКӨРСИ.

Аллааһө ләәәә иләәһә илләәһү әлхәййөль кайййүм. Ләәтөъхөзөһү синәтөү вәләә нәүм. Ләһү мәә фиссәмәвәти вәмәә фил әрд. Мәнзәлләзи йәшфәгө гиндәһүү илләә би изниһ. Йәгләмө мәә бәйнә әйдииһим вәмә халфәһөм. Вәләә йөхитүнә

бишэйъим мин гилмиһиини иллээ би мээшэээъ, вэсигэ көрсиййө һөссэмээвээти вэл эрд. Вэлээ йэъүүдөһүү хифзоһөммэ вэһүвэл гэлиййүлгэзыыйм,—дип укыйсың да, тэсбихның чуклы очын тотып Сөбөхэнэкэ я, Мэгбүд дип, 33 мэртэбэ сөбөхээналлаһи дип тэсбих тарта башлыйбыз. Аның артыннан килгэн эрерэк мэрҗэнне тотып Даимэн элхэмдө лиллэһи дибез дэ, 33 мэртэбэ Әлхэмдө лиллэһи дип тартабыз, шулай ук эре мэрҗэнне тотып Имэн, Аллааһө экбэр дибез (33 мэртэбэ) Аллааһө экбэр дип тартабыз. Йөзенчесен (чуклы башын) тотып Лэээ илээһэ иллэллааһө вэллааһө экбэр, лээхэүлэ вэлээ куүвэтэ иллэ биллээһил гэлиййил гэзыыйм дип тэмамлыйбыз. Моннан соң тэсбих догасы укыла.

## ТЭСБИХ ДОГАСЫ

### БИСМИЛЛЭЭҺИРРАХМЭЭНИРРАХИИМ

Аллааһөммэ тэкаббэл миннээ салээтэнээ вэсыййээмэнээ вэкыййээмэнээ вэ кыйрааъэтэнэ вэ рокүгэнээ вэ сөҗүдэнээ вэ когүдэнээ. Аллааһөммэ тэммим тэкосыйранээ вэ тэкаббэл тэмээмэнээ вэстэҗибө догаанээ вэгфир эхйээнээ, вэрхэм мэүтээнээ йээ мэүлээнээ. Аллааһөммэ эхфэзнээ йээ хафиз мин җэмиигил, бэлээйээ вэл эмраад.

Аллааһөммэ тэкаббэл миннээ һэдиһиссаалэтэл фэрда мэгэссөннэти мэгэ җэмиги нөкосаанээтиһээ бифэдликэ вэ кэрамикэ вэлээ тэдрибө биһэ вөҗүһэнээ йээ илэһэл гэлэмиин вэ йэ хайраннэсыйриин. Тэвэффэнээ мөслимиин, вэ эл хиконээ биссалихиинэ вэ саллэллааһө гэлээ хайри хальыйһи Мөхэммэдин вэгэлээ элиһи вэ эсхээбиһи эҗмэгиин.

Вэлхэмдөлиллэһи раббил гэлэмин.

Берэр сүрэ яки 2—3 аят укып, дога кылабыз.

Тэсбих догасы һэр намаз артыннан укылыр, шул сэбэпле бу доганың мэгнэсен белмэк кирэк.

Мэгнэсе:

Я, Раббем! Безнең намазыбызны, рузамезне, кыямыбызны, рокугымызны, сэҗдэмезне, кагдэмезне, тэсбихемезне, тэһлилемезне, тэвэззыгымызны вэ ялваруларымызны кабул кыйлгыл. Я, Раббем! Ҡимчелеклэремезне тэмам кыйлгыл, тэмам булган гэмэллэребезне кабул кыйлгыл вэ дэхи догамызны да кабул кыйлгыл. Әй, Хуҗамыз! Терекларемезне

ярлыкагыл вә үлекләремезгә рәхмәт кыйлгыл. Әй, рәхмәт кыйлгучы Аллаһ! Фазылың вә кәрамең илә бездән ошбу намазыбызны һәрбер кимчелекләре илә кабул кыйлгыл. Әл намаз илә безнең йөземезгә ормагыл. Әй, барча галәмнең Хак Мәгбүдө вә әй, ярдәм кыйлгучыларның камилерәге! Безне мөселман хәлемездә вафат кыйлгыл вә безләрне изге кешеләргә тоташтыргыл.

Аллаһы тәгалә халыкларның яхшырагы Мөхәммәд гәләйһиссәләмгә вә аның әһле вә сахәбәләрнең барчасына да рәхмәт кыйлгай идең.

## ХАТЫНЛАР намазы

Хатынлар намазының ирләр намазыннан 8 җирдә аермасы бардыр:

1. Ирләр намазга керешкәндә «тәкбир» илә кулларын колак йомшаклары турысына кадәр күтәрерләр. Хатынлар иңбашлары турысына кадәр генә күтәрерләр.

2. Намазга керешер өчен кул күтәргәндә ирләрнең куллары ачык булыр. Хатынларныкы җиңнәре эчендә өретүле булыр (яшерелгән).

3. Ирләр кыямда кулларын баглап, кендекләре астына куярлар. Хатынлар күкрәкләре өстенә генә куярлар.

4. Рокугда ирләр тезләрен бөкмәсләр, хатынлар бөгебе-рәк торырлар.

5. Рокугда вакытта, тезләренә таянып торганда, ирләрнең кул бармаклары арасы ачык булыр. Хатынларныкы ачык булмас.

6. Сәҗдәдә вакытта ирләр корсакларын, ботларын вә беләкләрен җиргә дә, кабыргаларына да тиермәсләр. Хатынлар ирләрнең хилафынча (киресенчә) кысылыбрак сәҗдә кыйлырлар.

7. Кәгдәдә вакытта ирләр уң аякларын бастырып, бармакларын кыйблага таба каратып куярлар да сул аякларын яткырып аның өстенә утырырлар.

8. Ирләр фарыз намазларын азан вә камәт укып, имам вә җәмәгать илә укырлар, хатынлар өчен азан вә камәт лазем түгелдер. Чөнки хатынларның арадан берсе имам булып, намазны җәмәгать булып укулары мәкруһдыр (гөнаһдыр).

Ошбу 8 җирдән башка урынларда хатынларның намазлары да ирләр намазы кебидер.

## Азан вә Камәт

Биш вакыт фарыз намазларының вә Җомганың вакыты кергәч азан уку вә фарызларны укыр алдыннан гына камәт уку сөннәттер.

Хатын-кызга азан әйтү дөрес булмас.

Азан сүзләре ошбулардыр:

**АЛЛААҺӨ ӘКБӘР**

4 мәртәбә әйтелә.

**ӘШҺӘДӨ ӘЛ ЛӘӘ ИЛӘӘҺӘ ИЛЛӘЛЛААҺӨ**

2 мәртәбә.

**ӘШҺӘДӨ ӘННӘ МӨХӘММӘДӘР РАСҮЛУЛЛААҺ**

2 мәртәбә

**ХӘЙЙӘ ГӘЛӘССАЛӘҺ**

2 мәртәбә

**ХӘЙЙӘ ГӘЛӘЛ ФӘЛӘХ**

2 мәртәбә

**ӘЛЛААҺӨ ӘКБӘР**

2 мәртәбә.

**ЛӘӘ ИЛЛӘӘҺӘ ИЛЛӘӘЛЛААҺ**

1 мәртәбә

Иртә намазының азанында **ХӘЙЙӘ ГӘЛӘЛ ФӘЛӘХ** дәп соң:

**ӘССАЛӘӘТӨ ХАЙРОМ МИНӘН НӘҮМ**

дисләр, ягъни: Намаз уку йокыдан яхшырактыр дигән сүз.

Азан әйтеп бетергәннән соң **Азан догасы** укыла:

Аллаһөммә Раббә һәәдиһиддәгвәтит тәәммәти, вәссаләәтил каааанмәти әәти, Мөхәммәдәнил вәсииләтә вәл фәдыыйләтә вәддәраҗәтәл гәәлийәтәррафигәтә, вәбәгәсһө мәкаамәм мәхмүдәниллләзии вәгәттәһө вәрзөкөнәә шәфәгәтәһү йәүмәл кыййәмәти иннәкә ләә төхлифөл миигәәдө.

Азан уку хатын-кызларга сөннәт түгел.

## КНУТ догасы

Аллааһөммә иннәә нәстәгинөкә, вә нәстәгфирокә, вә нөъминө бикә, вә нәтәвәккәлө гәләйкә, вә нөсни гәләйкәл хайра, нәшкөрокә вәләә нәкфөрок, вә нәхләгө, вә нәтрокө мәййәфҗөрок. Аллааһөммә иййәәкә нәгбөдө вәләкә нөсаллии

вә нәсҗөдө, вә иләйкә нәсгәә вә нәхфиде нәрҗу рахмәтәкә вә нәхшәә гәзәәбәкә иннә гәзәәбәкә билкөффәәри мөлхикө.

Мәгнәсе: Әй, ошбу камил азанның вакыты кергән намазның хуҗасы булгучы Аллаһ! Мөхәммәд гәләйһиссәләмгә ярдәмчелекне вә артыклыкны вә югары һәм өстен булган дәрәҗәне биргел. Вә дәхи аны Үзең вәгдә кылган бөек мактаулы урынга ирештергел. Вә дәхи кыямәт көнендә безгә аның шәфәгәтен насыйп иткел. Тәхкыйк, Син вәгдәңә һич хилафлык кыйлмыйсың.

## РАМАЗАН АЕ ХАКЫНДА.

Бу Рамазан ае шундый айдыр ки, бу айда Аллаһының нуры, кануны булган Кор'ән иңә башлады. Шул Кор'ән иңгән ай булганы өчен бик хөрмәтле ай дип аталды. Бу ай шатлык ае, пәйгәмбәребезгә китап иңгән ай. Бу ай догаларның кабул була торган ае. Аллаһ сөбөхәнә вә тәгәлә сезнең догаларыгызны кабул итүдә һәр вакыт якынмын ди. Аллаһы тәгәлә догаларыбызны кабул итүдә муен тамырларыгыз кебек якынмын ди.

Аллаһы тәгәлә бу Рамазан аен өчкә бүлә:

Беренче ун көне — рәхмәт ун көне ди.

Икенче ун көне — мәгфират ун көне ди,

Өченче ун көне — Аллаһының газабыннан котылып, рәхмәтенә ирешкән ун көн ди.

Аллаһы тәгалә һәр кайсыбызны рәхмәтенә алса иде.

Әмин.

Рамазан аенда сәхәр ашала кояш чыкканчы ике сәгат алдан.

Авыз ачабыз кояш баегачта.

Авыз ачкач та ахшам намазы укыйбыз.

### Ураза нияте.

Гәрәбчә ошбу сүзләрне укып, тел илә ният кылу мөстәхәбдер.

БИСМИЛЛӘӘҺИРРАХМӘӘНИРРАХИИМ

Нәвәйтө эн әсумә саумә шәһри Рамәдаанә. Минәл фәҗри иләл мәгрибы хаалисал лилләәһи тәгәәләә.

Мәгнәсе: Иләһи! ният кылдым ошбу көннең фарыз уразасын тотмакка, иртә сәхәрдән кичке ахшамгача.

Әмин.

догаларыбызны кабул кыл.

Авыз ачкач ошбу дога укыла:

БИСМИЛЛӘӘҺИРРАХМӘӘНИРРАХИИМ

Аллааһөммә ләкә сумтө, вә бикә әәмәнтө вә гәләйкә тәвәккәлтө вә гәләә ризкыйкә әфтартө, вәли сауми гәдин шәһри Рамәдаанә, нәвәйтө фәгфирли йә гаффәәро мәәкаддәмтө вәмәә әххартө.

Бирахмәтикә йәәәә әрхәмәрраахимиин.

Әмин.

Мәгнәсе:

Әй, Аллаһым! Ошбу рузамны мин синең өчен гәнә тоттым вә мин Сиңа гына иман китердем вә Сиңа тәвәккәл кыйлдым, вә Синең ризкың илә авызымны ачамын. Әй, гөнаһларны гафу иткүче Аллаһы! Инде минем әүүәлге гөнаһларымны да, соңгы гөнаһларымны да ярлыкагыл.

Әмин.

## ТӘРАВИХ НАМАЗЫ

Рамазан аенда һәр көн ястү намазыннан соң, витр вәҗеп намазыннан әүүәл тәравих намазы уку ирләргә дә, хатыннарга да сөннәттер.

Тәравих намазы арасында 4 рикәгат укыган саен укыр кадәр туктап тәравих кылу, ягни ял итеп тору сөннәттер.

Элек ясигы (ястү) намазы укыла.

Аннан соң 20 рикәгат тәравих намазының 4 рикәгатен үтәмәккә, йүнәлдем кыйбла тарафына (имам белән укыганда оедом ошбу хазер имамга дип әйтелә), Халисан лилләһи тәгәлә, Аллаһө әкбәр дип, калганын башка намазлар укыган кебек дәвам итәбез.

1 рикәгаттә Сөбөхәнәкә, Әлхәм, аннан соң:

Сәләәмөн гәлә нүхин фил гәәләмиин. Иннәә кәзәликә нәҗөзил мөхсиниин, иннәһү мин гибәәдинәл мө'миниин дип укыйбыз.

2 рикәгаттә: Әлхәм, аннан соң:

Сәләәмөн гәләә Ибөраһиим. Кәзәликә нәҗөзил мөхсиниин. Иннәһү мин гибәәдиәл мө'миниин — дип укыйбыз да эттәхиййәткә утырабыз, ярты эттәхиййәт укып, 3 нче рикәгаткә басабыз.

3 нче рикәгаттә Әлхәм, аннан соң:

Сәләәмөн гәләә Муусаа вә һааруун. Иннәә кәзәликә нәҗөзил мөхсиниин. Иннәһөмәә мин гибәәдинәл мө'миниин.

4 нче рикәгаттә Әлхәм, аннан соң:

Сәләәмөн гәләә Ильясин. Иннәә кәзәликә нәжөзил мөхсинийн. Иннәһү мин гибәдинәл мө'мининин.

Тәравих намазының һәр 4 рикәгатен укыган саен ошбу зекер әйтелә:

### Беренче 10 көндә

## БИСМИЛЛӘӘҺИРРАХМӘӘНИРРАХИИМ

Сөбөхәәнәзил мөлки вәл мәләкүт. Сөбөхәәнәзил гиззәти вәл гәзамәти вәл кодөрати вәл кибрийәъи вәл җәбәрүт. Сөбөхәнәл мәликил хәййилләзии ләәйәмүт. Сөббүүхөн коддүүсөр раббөл мәләәәәъикәти вәррух. Ләә иләәһә илләллааһә нәстәгфируллааһ, нәсъәлөкәл җәннәтә вә нәгүүззә бикә минәннәр.

### Икенче 10 көндә

## БИСМИЛЛӘӘҺИРРАХМӘӘНИРРАХИИМ

Сөбөхәәнәзил мөлки вәл мәләкүт. Сөбөхәәнәзил гиззәти вәл гәзамәти вәл көдөрати, вәл кибрийәәъи вәл, җәләәли вәл, җәмәәли вәл, кәмәәли вәл җәбәрут.

Сөбөхәәнәл мәликил мәгбүдө.
Сөбөхәәнәл мәликил мәксудө.
Сөбөхәәнәл мәликил мәсҗүдө.
Сөбөхәәнәл мәликил хәййилләзи ләә йәнәәмө вәлә йәзәәлө вәләә йәмүтө әбәдәә.

Сөббүхөн, көддүсөр раббөнәә, вә раббөл мәләәәәикәти вәррух. Ләәәә иләәһә илләәәллааһө нәстәгфируллааһ. Нәсъәлөкәл җәннәтә вә нәгүзө бикә минәннәәр.

### Ахыргы 10 көндә укый торган зекер.

## БИСМИЛЛӘӘҺИРРАХМӘӘНИРРАХИИМ

Гата кылдың Кәрам ханнан
Ки инсәнә олуг айдан.
Ничә фазлың әйләп изһәр
Гафу әйлә хаталардан.

Олуг кылдың ки айлардан
Бу айның хөрмәте инсан.
Ки һәр кем кылса бер гәмәл
Музагаф кыл ихсаныңдан.

Ки бәндәң без зәгиф коллар
Җәнабеңә орып йөзләр.
Күзебездән түгеп яшьләр
Үтенәбез нәвалыңнан.

Безнең тик гасый колларга
Гинятең фазыл әйлә.
Шәриф айның шәрәфәтен
Мияссәр кыл и, Аллаһым.

Ки инзәл әйләдең кор'ән
Ки хөрмәтең әйтеп чындан.
Кәләмең хөрмәти өчен
Без зәгифләрне кыл шадан.

Бу айда саим булганны
Кичен вә каим булганны.
Дога вә зарый кылганны
Кабул кыйл син, Тәгәлаллаһ.

Безнең кеби зәгиф коллар
Ни теләрә хәлен сөйләр.
Ки фазлыңдан өмет әйләп
Гата кыйлгыл, Кәрималлаһ.

Ничә еллар түгеп яшьләр
Хозурыңа сөреп йөзләр.
Безнең тик жаһи колларың
Үтенәләр ки фазлыңнан.

Аларның хөрмәте өчен
Догаларның шамулы өчен.
Бу гасый би нәвәләрне
Ерак кыйлма җәвәрыңдан.

Хәбибең хөрмәте бардыр
Җәнабеңә әя, Сөбхан.
Хәбибең өммәтеннән без,
Безне гафуың кыл шадан.

Нә булса Синнән сорарбыз,
Үзең Син сән Кәрим мәннән.
Ки Синнән гайри кемсәне
Ки белмәдек, Тәгәлаллаһ.

Ки бәндәңнең хозурына
Нәзәр кыйлма әя, Ханнан.
Ки фазлыңдан гафу әйләп,
Рәхим кыйлгыл, Тәгәлаллаһ.

Ни әйтсәм дә зәгиф телдән,
Нә булсын бу гаҗиз колдан.
Шәрәфәтле шәриф айдан,
Насыйп ит я, Кәрималлаһ.

Өмет әйләп мөселманнар
Бу мәсҗедкә җыелганнар
(яки бу урынга җыелганнар).
Теләрләр күтәреп әлләр
Рыйзаңны я, Кәрималлаһ.

Әмин.

Тәравих намазының 20 рикәгатендә укыгач, ошбу дога укыла:
Аллааһөммә салли гәәлә Мөхәммәдиө вәгәләәәә әәли Мөхәммәдиө вәсаллим. Аллааһөммә зәиннәә бизиннәтил иимәәни вә шәрифнәә бишәраафәтил һидәәйәти вәл гирфәән, вә экримнәә бисыййәәми шәһри Рамәдәәнә вәрзөкөнәл җәннәтә вәл гөфраанә вә тәкаббәл миннәә тәраавихинәә йәә сөбөхәән вәстәҗибө догаааа әнә йәә мәннәәәнө бифәдликә вә җөдикә йәә мәннәәнө.

Бирахмәтикә йәә әрхамәрраахимиин.

Мәгнәсе!

Я, Раббем! Мөхәммәд гәләйһиссәләмгә вә аның җәмәгәтләренә рәхмәт вә сәләм кыйлгыл. Я, Раббем! Безләрне иман зиннәтләре белән зиннәтләгел вә дәхи гилем вә тәүфик илә шәрәфәтле кыйлгыл, рузамыз илә хөрмәтле кыйлгыл, безгә җәннәтне вә барлыкны насыйп кыйлгыл.

Я, Раббем! Безнең тәравихларыбызны кабул кыйлгыл. Я, рәхмәт кыйлучы Аллааһы! Фазлың вә кәрамың илә безнең догаларыбызны кабул кыйлгыл. Я, камил рәхмәт кыйлгучы Аллааһы тәгәлә! Һәр нәрсә синең рәхмәтең илә гөнә булгучыдыр.

Моннан соң 3 рикәгат витр вәҗеп намазы укыла.

Азактан берәр сүрә вә аятләр укып, дога кылып куябыз.

## ТӘРАВИХ НАМАЗЫН УКУНЫҢ ХАСИЯТЛӘРЕ

Хәзрәти Гәли разиаллааһыдан риваяттер:

Рамазан аенда укылган тәравих намазының фәзыйләтләре:

ӘҮҮӘЛГЕ КИЧТӘ бер мө'мин тәравих намазын укыса — ярлыканыр аның барлык гөнаһлары.

Аллаһы сөбхәнә вә тәгаләә синең гамәлләреңне кабул итеп, өмет иткән дәүләтенә ирештерде вә гөнаһларыңны ярлыкады диерләр.

ИКЕНЧЕ КИЧӘДӘ УКЫСА — Хак тәгалә хәзрәтләре анасының вә атасының гөнаһларын ярлыкар.

ӨЧЕНЧЕ КИЧӘДӘ УКЫСА — фәрештәләр әйтерләр: «Я, мө'мин! Аллаһы тәгалә синең гибәдәтеңне кабул итеп, гөнаһларыңны гафу-мәгфират итте»,— дип.

ДҮРТЕНЧЕ КИЧӘДӘ УКЫСА — Тәуратны, Инҗилне, Забурны, Кор'әнне хәтем кыйлган савап булыр (хәтем — китапны тулысынча укып чыгу).

БИШЕНЧЕ КИЧӘДӘ УКЫСА — Мәккә-Мәдинәдә мәсҗедем Харам вә мәсҗедем Аксада намаз укыган савабы бирелер.

АЛТЫНЧЫ КИЧӘДӘ УКЫСА — Бәйтелмәгмурны тәвваф кыйлган савабы вә аның һәр ташы ул мө'мин өчен ярлыкауны өстәрләр (теләрләр).

ҖИДЕНЧЕ КИЧӘДӘ УКЫСА — Муса гәләйһиссәләм Фиргәвен илә сугыш кылгандагы савабы бирелер.

СИГЕЗЕНЧЕ КИЧӘДӘ УКЫСА — Пәйгәмбәребез илә Бәдер сугышында бергә булган кеби булыр.

ТУГЫЗЫНЧЫ КИЧӘДӘ УКЫСА — Дауд гәләйһиссәләм илә бергә гибәдәт кылган савабы булыр.

УНЫНЧЫ КИЧӘДӘ УКЫСА — дөнья вә әхыйраттә сәләмәт булыр барча куркулардан.

УНБЕРЕНЧЕ КИЧӘДӘ УКЫСА — кабул булмыш сөннәт хәҗәтенең савабы бирелер.

УНИКЕНЧЕ КИЧӘДӘ УКЫСА — сыйратны елтыр кеби үтәр.

УНӨЧЕНЧЕ КИЧӘДӘ УКЫСА — Бәйтүлмукаддәсне бина кыйлган савабы бирелер.

УНДҮРТЕНЧЕ КИЧӘДӘ УКЫСА — кадер кичәсендә уяг торган савабы бирелер.

УНБИШЕНЧЕ КИЧӘДӘ УКЫСА — хәҗәте үтәлер, догасы кабул булыр, әхыйраттә дәрәҗәләр бирелер.

УНАЛТЫНЧЫ КИЧӘДӘ УКЫСА — дөньядан үткәндә

вә кыяматтә кәлимә и таибәне әйтер: «Лә иләһәә илләллааһә Мөхәммәдәррасулуллааһ» дип.

УНҖИДЕНЧЕ ҖИЧӘДӘ УКЫСА — җәннәти Әгләда урынын күрмәенчә дөньядан чыкмас.

УНСИГЕЗЕНЧЕ ҖИЧӘДӘ УКЫСА — шәһидләр вә сугыш кылучыларның саваплары кеби әҗер бирелер.

УНТУГЫЗЫНЧЫ ҖИЧӘДӘ УКЫСА — дөнья вә әхыйраттә ярдәмче булыр.

ЕГЕРМЕНЧЕ ҖИЧӘДӘ УКЫСА — Пәйгәмбәребезне төшендә күрмичә дөньядан чыкмас.

ЕГЕРМЕБЕРЕНЧЕ ҖИЧӘДӘ УКЫСА — Җир вә күктәге фирештәләр аны ярлыкауны өстәрләр вә Аллаһының ризалыгын табар.

ЕГЕРМЕИКЕНЧЕ ҖИЧӘДӘ УКЫСА — Мөхәммәд Мостафа салләллааһу гәләйһи вәсәлләм өммәтендәге ятимнәрне вә колларны ризык биреп туйдырган савабы бирелер.

ЕГЕРМЕӨЧЕНЧЕ ҖИЧӘДӘ УКЫСА — Мөхәммәд Мостафа салләллааһу гәләйһи вәсәлләм өммәтендәге тоткыннарны азат кыйлган кеби булыр.

ЕГЕРМЕДҮРТЕНЧЕ ҖИЧӘДӘ УКЫСА — китабы (гәмәл дәфтәре) уң яктан бирелер.

ЕГЕРМЕБИШЕНЧЕ ҖИЧӘДӘ УКЫСА — үлем фирештәсе күркәм сүрәттә килер, җәннәт беләп сөенеч биреп җанын алыр.

ЕГЕРМЕАЛТЫНЧЫ ҖИЧӘДӘ УКЫСА — үлгәндә Аллааһы тәгаләнең ярдәме беләп фирештәләр шәйтан хәйләсеннән сакларлар.

ЕГЕРМЕҖИДЕНЧЕ ҖИЧӘДӘ УКЫСА—Аллааһы тәгаләнең әмере белән җәһәннәм капугысы багланыр.

ЕГЕРМЕСИГЕЗЕНЧЕ ҖИЧӘДӘ УКЫСА—Аллааһы тәгалә оҗмах сакчыларына әйтер: «Оҗмах капугыларын ач! Теләсә кайсысына керсен дәю.

ЕГЕРМЕТУГЫЗЫНЧЫ ҖИЧӘДӘ УКЫСА — Әюб гәләйһиссәләм авыруына сабыр иткән савапны бирер вә гөнаһлары ярлыканыр.

УТЫЗЫНЧЫ ҖИЧӘДӘ УКЫСА—Аллааһы тәгаләнең

әмере илә ГӘРШ астында бер мөнәди кычкырыр: Тәравих укыганнар тәмугдан котылмышлар, өмет иткән оҗмахларына вә дидарын күрү дәрәҗәсенә ирешteләр. Аллааһы тәгаләнең олуглыгы белән ант итеп әйтә: ул колларны гафу иттем дип, тамугка тәннәрен харам иттем дип. Аннан соң Аллааһы тәгалә боерыр: шуларның һәркаюсы өчен: кирәк ир, кирәк хатын булсын, барчасының кулына ышаныч кәгазе язып бирергә җәһәннәмнән котылганлыкка вә сыйратны тиз кичкәнлеккә яраклы кәгазне бирер.

Һәркем ихлас белән укыса тәравих намазын, шиксез бу савапларга ирешер.

Әмин.

## НАМАЗ ХАКЫНДА

Әүвәле Аллааһыны белгәннән соң бәндәнең кыямәт көнендә соралачак нәрсәсе намаздыр.

Намаз мө'миннең нурыдыр.

Намазны әүвәлге вакытында уку гәмәлнең иң хәерлеседер.

Намаз диннең терәгедер, кем торгызса намазны — ул торгызыр динне.

Мө'мин белән кәфер арасын намаз аерадыр.

Намазны ялгыз укуга караганда җәмәгәт белән укуның дәрәҗәсе 27 мәртәбә артыктыр.

## ДОГА РӘХМӘТ АЧКЫЧЫ, ТӘҺӘРАТ НАМАЗ АЧКЫЧЫ, НАМАЗ ҖӘННӘТ АЧКЫЧЫ.

Бер мәп (кеше) калдырса иртәнге намазын, бизәр аннан иман.

Бер мән калдырса өйлә намазын, бизәр аннан Кор'ән.

Бер мәп калдырса икенде намазын, бизәр аннан мөрсәл пәйгәмбәрләр.

Бер мән калдырса ахшам намазын, бизәр аннан олуг фирештәләр.

Бер мәп калдырса ясигы (ястү) намазын, бизәр аннан Аллааһө үзе (Аллааһ сакласын).

Ашыгыгыз намазга вакыты чыкмастан элек, ашыгыгыз тәүбәгә үлем килмәстән элек.

ШУЛАЙ УК:

Бер мән укымаса иртәнге намазын — булмас аның ризыгында бәракәт.

Бер мән укымаса өйлә намазын, булмас аның йөзендә нур.

Бер мән укымаса икенде намазын, булмас аның әгзасында көч куүвәт.

Бер мән укымаса ахшам намазын, булмас аның ризыгында **ләззәт.**

Бер мән укымаса ясигы намазын — ул кеше мө'мин булмас.

Әгәр бала уң ягыннан сул ягын аерса, бәс кушыгыз аны намазга.

## НАМАЗ ЭЧЕНДӘГЕ ДОГАЛАРНЫҢ МӘГНӘЛӘРЕ

### ӘЛХӘМ — Фәтиха сүрәсе.

БИСМИЛЛӘӘҺИРРАХМӘӘНИРРАХИИМ

Әлхәмдө лилләәһи раббил гәәләмиин — һәрбер мактаулы сыйфатлар барча гәләмне тәрбия кылучы гибәдәт кыйлырга тиешле булган зат (ягни, намаз торгызырга тиешле булган зат) бер Аллаһы тәгәләгә генә хастыр

ӘРРАХМӘӘНИРРАХИИМ — дөньяда барлык мәхлүкәтләргә рәхмәт кыйлучы ул Аллаһы тәгәлә (яхшысына да, яманына да), рәхиме кыямәт көнендә мө'миннәргә генә. Мө'миннәр кемнәр? Аллаһының боерыгын үтәп, тыйган эшләреннән тыелучылардыр.

МӘӘЛИКИ ЙӘҮМИДДИН — Кыямәт көнендә дөньяда эшләгән эшләребездән җавап бирәсебез бар, Шул Кыямәт көненең падишасы ул Аллаһы тәгәлә.

ИЙЙӘӘКӘ НӘГБӨДӨ — Сине берлибез вә сиңа камил түбәнчелек белән гибәдәт кылабыз.

ВӘ ИЙЙӘӘКӘ НӘСТӘГИИН — Синнән генә ярдәм өстибез.

ИҺДИНӘССЫЙРААТАЛ МӨСТӘКЫЫЙМ — күндергел син безләрне туры юлга.

СЫЙРААТАЛЛӘЗИНӘ ӘНГӘМТӘ ГӘЛӘЙҺИМ — шундаен әдәмнәр юлына ки, пәйгәмбәрләр юлына, изгеләр юлына.

ГАЙРИЛ МӘГДҮБИ ГӘЛӘЙҺИМ

ВӘЛӘДДАААЛЛИИН — азып, тузып, Үзеңне инкар итеп йөрүче әдәмнәр юлыннан безләрне ерак кыл.

ӘМИН — догаларыбызны кабул кыйл.

**Иннә эгтайнәнең мәгнәсе:**

Иннәә эгтайнәәкәл кәүсәр — Тәхкыйк, сезгә бирдек без иге-чиге булмаган нигмәтләрне.

Нинди нигмәтләр бирде?

1. Иман белән тудырды
2. Қор'ән иңдерде.
3. Шул кор'әнне өйрәтергә пәйгәмбәрләр җибәрде.
4. Ислам нигмәте
5. Гакыл нигмәте
6. Ис сизү нигмәте,
7. Қүз күрү нигмәте
8. Қояш нигмәте
9. Һава нигмәте
10. Су нигмәте
11. Ризык нигмәтләре һәм башкалар, нигмәтләрнең чиге юк. Кыямәт көнендә мө'мин коллары сугарыла торган Кәүсәр чишмәсе бирдек, ул чишмә үзенең өммәтләренә хастыр.

ФӘСАЛЛИ ЛИ РАББИКӘ ВӘНХӘР — шушы нигмәтләр бәрабәренә торгыз

ИННӘӘ ШӘӘНИЪӘКӘ ҺҮВӘЛ ӘБӨТӘР—раббың ризалыгы өчен намаз һәм корбан бугазлагыл (чалгыл), (ятим-фәкирләргә өләшкел), дөреслектә синең дошманнарың-ның исеме югалачактыр. Синең әмереңне үтәмәүчеләр һәр хәердән киселүчеләрдер.

## КОЛЬҺҮАЛЛАҺ СҮРӘСЕ

КОЛЬҺҮАЛЛАҺӨ ӘХӘДӨ — Әйткел син и, Мөхәммәд Мостафа салләллаһу гәләйһиссәләм: ул гибәдәт кыйлырга тиешле булган зат,

ягни намаз торгызырга тиешле булган зат Аллаһы тәгалә бер генәдер.

АЛЛААҺӨССАМӘДЕ — Ул Аллаһы тәгалә ихтияҗсыз камил хуҗадыр.

ЛӘМ ЙӘЛИДӨ — Ул һич кемне тудырмады,

ВӘ ЛӘМ ЙҮЛӘДӨ — Үзе дә һич кемнән тумады

ВӘЛӘМ ЙӘКӨЛЛӘҺҮ КӨФӨВӘН ӘХӘДӨ—һичкем, һич нәрсә аңа тиңдәш булмады, охшаш булмады.

Намазда рокугга бөгелгәч:

СӨБӨХӘНӘ РАББИӘЛ ГӘЗЫЙМ — олуг булган Раббемезне кимчелекләрдән паклыймын.

Каумәгә күтәрелгәндә (ягни, аяк өстенә басканда):

СӘМИГАЛЛААҺӨ ЛИМӘН ХӘМИДӘҺ—Аллаһы тәгалә үзенең мактаучысының сүзен ишетәдер.

Тураеп беткәч:

РАББӘНӘ ЛӘКӘЛ ХӘМДӨ — И, Раббымез! һәрбер мактаулылык сиңа гына хастыр.

Сәҗдәдә укыла:

СӨБӨХӘНӘ РАББИӘЛ ӘГЛӘ — Әглә булучы Раббемезне пак дип беләмен.

## ЭТТӘХИЙЙӘТ — ТӘШӘҺҺӨД

ЭТТӘХИЙЙӘӘТӨ ЛИЛЛӘӘҺИ ВӘССАЛӘВӘӘТӨ ВӘТТАЙИЙБӘӘТӨ — тел гибәдәтләре дә, тән гибәдәтләре дә һәр каюсы Аллаһы тәгалә өчендер.

ЭССӘЛӘӘМӨ ГӘЛӘЙКӘ ӘЙЙӨҺӘННӘБИЙЙӨ ВӘ РАХМӘТУЛЛААҺИ ВӘ БӘРАКӘТӨҺӨ — И, Пәйгәмбәремез! Сиңа Аллаһы рабыңның сәләме вә рахмәте вә бәракәте булсын.

ЭССӘЛӘӘМӨ ГӘЛӘЙНӘӘ ВӘ ГӘЛӘӘ ГИБӘӘДИЛЛӘҺИССАЛИХИИН — сәләм безгәдә һәм Аллаһы тәгаләнең һәрбер изге бәндәләренә булсын.

ӘШҺӘДӨ ӘЛ ЛӘӘ ИЛӘӘҺӘ ИЛЛӘЛЛАҺӨ ВӘ ӘШҺӘДӨ ӘННӘ МӨХӘММӘДӘН ГӘБӨДӨҺӨ ВӘ

РАСҮЛӨҺӨ — чын күңлемнән гуаһлык бирәмен ки бер Аллаһыдан башка һич бер зат иләәһ була алмый һәм анардан башка һич бер затка гыйбәдәт кылу дөрес түгел дип.

Әмин.

Бу эттэхиййәт өч төрле затның сүзидер. Расүлемез Раҗәб аеның 27 нче кичендә Аллаһы тәгаләнең әмри илә күккә (миграҗга) ашди. Шул вакыт Расүлемез Аллаһы тәгәләгә хәмед әйтди (эттэхиййәтө лилләһи вәссаләвәтө) дип. Соңра Аллаһы тәгалә (Әссәләмө гәләйкә әййөһәннәбиййө вә рахмәтуллаһи вә бәракәтөһө) дип җавап бирди. Соңыннан Расүлемез моңа каршы Әссәләмө гәләйнә вә гәлә гибәдилләһиссалихин) дидектә, фәрештәләр (Әшһәдө эл ләә иләәһә илләллаһө вә эшһәдө әннә Мөхәммәдән гәбдөһө вә расүлөһө) диделәр, бәс эттэхиййәттә өч затның сүзи булды. Шул сәбәпле һәрберсен әйткәндә туктарга кирәк.

Мәсәлән: вәттаййибәтө дигәч сулу алып, вә бәракәтөһүгә тик сулу алып, вә гәлә гибәдилләһиссалихингә тик укыр, соңра сулу алып гәбдөһү вә Расүүлөһүгәчә укылыр.

## САЛАВАТНЫҢ МӘГНӘСЕ

Аллаһөммә салли гәләә Мөхәммәдин вәгәләә әәли Мөхәммәд.

Я, Рабби! Мөхәммәд гәләйһиссәләмгә аның каумәнә рәхмәт кыйл.

Кәмәә салләйтә гәләә Ибөраһиимә вә гәлә әәли Ибөраһимә иннәкә хәмидөм мәҗидө.

Нитәки (ничек) Ибөраһим гәләйһиссәләмгә вә аның каумәнә рәхмәт кыйлмыш идең, тәхкыйк син мактаулы, олугсың.

Аллааһөммә бәәрик гәәлә Мөхәммәдин вә гәләә әәли Мөхәммәд.

Я, Раббем! Мөхәммәд гәләйһиссәләмгә вә аның каумәнә мөбәрак биргел.

Кәмәә бәәрактә гәләә Ибөраһиимә вә гәләә әли Ибөраһиимә иннәкә хәмиидөм мәҗидө.

Нитәки Ибраһим гәләйһиссәләм вә аның каумәнә мөбәраклек бирмеш идең, вә, тәхкыйк, син мактаулы вә олугсың.

Сәләм биргәндә әйтелә:

ӘССӘЛӘӘМӨ ГӘЛӘЙКӨМ ВӘ РАХМӘТУЛЛААҺ—Сезгә Аллаһы тәгәләнең сәләме вә рахмәте булсын.

Сәлам догасы!

АЛЛААҺӨММӘ ӘНТӘССӘЛӘМӨ ВӘ МИНКӘССӘЛӘМӨ ТӘБӘРАКТӘ Я ЗӘЛ ҖӘЛӘЛИ ВӘЛ ИКРАМ—Я, Раббем! Син һәрбер бәләләрдән саклагучысың, һәрбер сәләмәтлек синнән генәдер. Мөбәрак булгучысың. И, олуглык вә рахмәт иясе Аллаһ.

## РАББӘНӘНЕҢ МӘГНӘСЕ

БИСМИЛЛӘӘҺИРРАХМӘӘНИРРАХИИМ

Раббәнәәәә әәтинәә фиддөнйәә хәсәнәтәү вә фил әәхыйрати хәсәнәтәү вә кыйнәә гәзәбәннәәр.

И, Раббем! Дөньялыкта безгә изгелек эшли торган гөмер бир. Шушы изгелегебез бәракәтендә әхыйраттә җәннәтеңне насыйп ит, ут газабыннан саклагай идең.

Әмин

## КАДЕР КИЧӘСЕНДӘ

укыла торган намаз (Рамазан аенда).

Кадер кичәсендә дүрт рикәгат намаз укыла, һәр рикәгатендә Фәтиха (Әлхәм) сүрәсеннән соң Иннә әнзәлнәһ сүрәсе биш мәртәбә укыла, вә дәхи сүрә Ихласны (Кольһүаллаһны) 5 мәртәбә укыла. Намаздан соң 70 мәртәбә Әстәгфируллаһә вә әтүбө иләйһи дип әйтергә кирәк.

## ИННӘ ӘНЗӘЛНӘҺ СҮРӘСЕ

Иннәәәә әнзәлнәәһө фии ләйләтил кадр. Вәмәәәә әдөраакә мәә ләйләтөл кадр. Ләйләтөл кадри хайром мин әлфи шәһр Тәнәззәлөл мәләәәәъикәтө вәррухө фииһәә би изни раббиһим мин көлли әмр. Сәләмөн һия хәттәә мәтөләгил фәҗр.

## КӘЛИМӘТИ ИМӘН

Кәлимәтөн тайййибәтөн ләәәә иләәһә илләллаһө Мөхәммәдөррасүлуллаһ. Кәлимәтөшш әһәдәти әшһәдө әл ләәәә иләәһә илләллааһө вә әшһәдө әннә Мөхәммәдән гәбәдөһү вә расүлөһө.

## КӘЛИМӘТӨТТӘҮХИДИ

Әшһәдө әл ләәәә иләәһә илләллааһө вәхдәһү ләә шәрикә

ләһ. Ләһөл мөлкө вә ләһөл хәмдө йөх'ий вә йөмитө. Вәһүә хәййөл ләә йәмүтө. Бийәдиһил хайро вәһүә гәлә көлли шәй ин кадир.

## КӘЛИМӘТӨ РАДДИЛКӨФРИ

Аллаһөммә инниими әгүдө бикә мин ән өшрикә бикә шәй әү вә әнә әгләм, вә әстәгфирокә лимә ләәәә әгләме Иннәкә әнтә гәлләәмөл гойүбө.

## КӘЛИМӘТӨЛ ИСТИГФӘРИ

Әстәгфироллааһә, әстәгфироллаәһә, әстәгфироллаһә тәгәлә, мин көлли зәмбин әзнәбөтөһө гәмдән әү хатаән сирран әү гәлә нияһ. Вә әтүбө иләйһи минәззәмбилләзии әгләмө вә минәззәмбилләзии ләәәә әгләм. Иннәкә әнтә гәлләәмөл гойүбө.

## КӘЛИМӘТӨТТӘМҖИДИ

Сөбөхәәнәллааһи вәлхәмдө лилләәһи вә ләәәә иләәһә илләәллаһө вәллааһө әкбәр. Ләә хәүлә вәләә куүвәтә илләә билләәһил гәлиййил гәзыйм. Мәшәәәәъәллааһө кәәнә вәмәә ләм яшәә ләм йәкөн. Әл имәәнө икорарөм биллисәни вә тәсдиком билкалби бимә җәәәәъә биһии мин гиндилләәһи Мөхәммәдөр расүлүллааһи салләллааһө гәләйһи вәсәлләм.

Имәнөм мөҗмәлөн. Әәмәнтө билләәһи кәмәә һүә би әсмәәәәъиһии вә сыйфәәтиһии вә кабилтө җәмигә әхкәәмиһ.

## ИМӘНӨМ МӨФӘССАЛӨН

Әәмәнтө билләәһи вәмәләәәәъикәтиһии вә көтөбиһии вә росөлиһии вәлйәүмил әәхыйри вәлкадәри хайриһии вә шәрриһии минәллааһи тәгәләә вәлбәгси бәгдәл мәүт.

### Иман китерү сүзенең мәгнәсе.

## ЛӘ ИЛӘӘҺӘ ИЛЛӘЛЛААҺӨ

Без гибәдәт кылырга (сыгынырга, ярдәм сорарга) яраклы башка затлар юк, мәгәр бер Аллаһы тәгәлә генәдер.

## МӨХӘММӘДӨРРАСУЛҮЛЛААҺ

Мөхәммәд Мостафа салләллаһө гәләйһи вәсәлләм. Ал-

лаһы тәгаләнең турылыклы илчеседер: бәндәләргә шәригать хөкемнәрен өйрәтеп, гәмәлдә эшләп күсәтүчеседер.

Иман хакында пәйгәмбәребезнең хәдисләре.

Бер мән үзен таныса, тәхкыйк Аллаһыны таныр.

Иман ялангачтыр: аның киеме тәквәлектер, зиннәте аның хаядыр, ояттыр, аның җимеше гилемдер.

Танығыз Аллаһыны рәхәт вакытыгызда, таныр ул сезнс авырлыкка төшкәндә.

Кем рәхмәт кылмаса әдәмнәргә, Аллаһ аңа рәхмәт кылмас.

Бер мән оялмаса әдәмнәрдән, оялмас Аллаһыдан.

Ватанны сөю иманнандыр.

Һич бер әдам камил мөселман булмас шул вакыткача, үзенә сөйгән нәрсәне кәрдәшенә сөйгәнгәчә.

Әдәплелек, оятлылык иманнандыр.

Сүздә тормак, вәгдәсен җиренә җиткермәк иманнандыр.

Мө'миннең иманда камилрәге холык йөзеннән камилрәгедер.

## ИМАННЫҢ МӘГНӘСЕ

Кәлимәти имән.

БИСМИЛЛӘӘҺИРРАХМӘӘНИРРАХИИМ

Кәлимәтөн тайиибәтөн — Хуш, күркәм сүз ошбудыр.

Ләә иләәһә илләллаһө—Хак гибәдәт кылырга тиешле булган зат Аллаһы бер генәдер.

Мөхәммәдөр расулуллааһ—Мөхәммәт Мостафа салләллаһу гәләйһиссәләм Аллаһы тәгаләнең ислам динен бәндәләргә белдерергә җибәргән илчеседер.

Кәлимәтөшшәһәәдәти—Аллаһының берлегенә вә расулнең хаклыгына гуаһылык бирә торган сүз ошбудыр.

Әшһәдө әл ләәәә иләәһә илләллааһө Гуаһылык бирәмен — бер Аллаһы тәгалә генә хаклык үзрә коллык кылынмыш заттыр, ягни, намаз торгызырга тиеш булган зат.

вә әшһәдө эннә Мөхәммәдән — Дәхи гуаһылык бирәмен — дөреслектә

гәбдөһү вә расүлөһү—Мөхәммәд Мостафа салләллаһө гәләйһи вәсәлләм — ул Аллаһының колы, Расүле, Аллаһы тәгаләнең ислам динен өйрәтергә җибәрелгән илчеседер.

КӘЛИМӘТӨТТӘҮХИДИ — Аллаһы тәгаләне берли торган сүз ошбудыр.

Әшһәде әл ләәәә иләәһә илләллааһө — Бер Аллаһы тәгәлә генә хаклык үзәрә коллык кылынмыш зат.

вәхдәһү ләә шәрикә ләһ—Аллаһы тәгәләнең ширке — тиңдәше юк.

Ләһөл мөлке — Ул Аллаһы тәгәлә генә камил падишаһ.

вә ләһөл хәмдө — ул Аллаһы тәгәләдән генә барча мактаулмыш сыйфатлы эшләрнең булуы барлык мактау ул Аллаһы тәгәләгә генә һасдыр.

йөх'ий вә йөмитө — тергезер ул Аллаһы тәгәлә вә үтерер ул Аллаһы тәгәлә

Вәһүә хәййөл ләә йәмүтө — Ул Аллаһы тәгәлә терек булучы, ул мәңге үлмәс.

Бийәдиһил хайро вәһүә гәләә көлли шәй ин кадиир—Ул Аллаһы тәгәлә барча нәрсәгә шиксез көче җиткүчедер. Бөтен хәерле эшләрдә ул Аллаһы тәгәләдән генәдер.

КӘЛИМӘТӨ РАДДИЛКӨФРИ — Иман бозылып көферлеккә төшүдән саклый торган сүз ошбудыр.

Аллааһөммә иннииии — И, Аллаһым! Дөреслек белән мин

Әгүзө бикә мин ән өшрикә бикә шәй әү—Сыгынамын я, Раббем, сиңа ширек-тиңдәш куюдан бер нәрсәне.

вә әнә әглəм — белә торып тиңдәш куюдан үзеңнән сыгынамын. Белеп кылган гөнаһларымнан гафу үтенәмен.

вә эстәгфирокә — вә ярлыкау өстимен синнән.

лимәә ләәәә әглəм—белми кылган көфер эшләр өчен гафу үтенәмен.

Инләкә әнтә гәлләәмөл гойүбө — Дөреслектә син генә я, Раббем, гаепләрне белүчесең.

КӘЛИМӘТӨЛ ИСТИГФӘРИ — Аллаһы тәгәләдән ярлыкауны өсти торган сүз ошбудыр.

Әстәгфироллааһә, әстәгфироллааһә, әстәгфироллааһә — тәгәлә Ярлыкауны өстимен мин Аллаһы тәгәләдән.

мин көлли зәмбин — барча гөнаһларымны ярлыкауны өстимен (сорыймын).

әзнәбөтөһү гәмдән — кылдым мин ул гөнаһны ихтиярым белән

әү хатаән сирран — яки хаталык белән, яки яшерен кылдым ул гөнаһны.

әү гәлә нияһ — яки әшкәрә (ачык) кылдым ул гөнаһларымны

вә әтүбө иләйһи — вә тәүбә кылдым, кайттым ул Аллаһы тәгаләгә

минәззәмбилләзии әгләмө — шундаен гөнаһлардан, белеп кылдым ул гөнаһларны

вә минәззәмбилләзи ләәәә әглөм — белми торган гөнаһлардан тәүбә итәмен

Иннәкә әнтә гәлләәмөл гойүбө — Дөреслектә я, Раббем, син генә барча гөнаһларны белүче

ҠӘЛИМӘТӨТТӘМҖИДИ — Аллаһы тәгаләне олуглый торган сүз ошбудыр

Сөбөхәәнәллааһи — Аллаһы тәгалә барча кимчелектән пактер

вәлхәмдөлилләәһи — барча мактаулы эшләрне кылучы Аллаһы тәгалә генәдер

вә ләәәә иләәһә илләәллаһө — хаклык үзәрә коллык кылынмыш зат Аллаһы тәгалә генәдер, башка зат юктыр.

вәллааһө әкбәр — дәхи Аллаһы тәгалә барча нәрсәдән олугыдыр

Лә хәүлә вәләә куүвәтә — Бер хәлдән икенче хәлгә әйләндерүче зат юктыр.

иллә билләәһил гәлиййил гәзыыйм — Аллаһы тәгаләнең ярдәме белән генәдер, бик олугы булгучы ул Аллаһы тәгалә

Мәшәәәәъәллааһө кәәнә—Ни нәрсәнең булуын теләсә ул булыр

вәмә ләм яшә ләм йәкөн — ни нәрсәнең булуын теләмәсә ул нәрсә булмыйдыр

Әл имәәнө икорарoм биллисәәни — Иман дигәнебез әйтмәкебез тел белән.

вә тәсдиком билкалби — Ышанмак, растка тотмак күңел белән.

бимәә җәәәәъә биһии—шул хөкемнәргә ки килде ул хөкемнәр белән.

Мин гиндилләәһи — Мөхәммәдөр расүлүллааһи — Мөхәммәд Мостафа салләллаһө гәләйһи вәсәлләм. Аллаһы тәгәләнең дин-исламны белдерергә җибәргән илчеседер

саллэллааһө гәләйһи вәсәлләм — Аллаһы тәгәлә рәхмәт кылсын ул Мөхәммәд Мостафа салләллаһу гәләйһи вәсәлләмгә, дәхи Аллаһы тәгәлә сәләмәт кылсын иде

Имәәнөм мөҗмәлөн — Барча хөкемнәрне җыеп, кыскалык белән иман китерү ошбудыр

Әәмәнтө билләәһи — Ышандым Аллаһы тәгәләнең барлыгына, берлегенә

кәмәә һүә би әсмәәәәъиһии — Аллаһы тәгәләгә ышанган кеби ышандым ул Аллаһы тәгәләнең барча исемнәренә

вә сыйфәәтиһи — ул Аллаһы тәгәләнең барча сыйфатларына

вә кабилтө җәмигә әхкәәмиһ — вә кабул кылдым ул Аллаһы тәгәләнең барча хөкемнәрен

ИМӘНӨМ МӨФӘССАЛӨН — Аерып иман китерү ошбудыр

Әәмәнтө билләәһи — Ышандым Аллаһы тәгәләнең барлыгына вә берлегенә.

вәмәләәәә икәтиһии — вә ышандым Аллаһы тәгәләнең барча фәрештәләренә: (Җәбраил — вәхи (хәбәр) китерүче, Микаил — жил, болытлар кубаручы, Исрафил — сур өрүче, Газраил — җан алучы, Кираман-Кәтибин — ике иңебездәге ике фәрештә).

вә көтөбиһии — ул Аллаһы тәгәләнең барча китапларына инандым: Таурат — Муса пәйгәмбәргә, Забур — Даут пәйгәмбәргә, Инҗил — Гәйса гәләйһисәлләмгә, Көр'эн — Расүлебез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу гәләйһи вәсәлләмгә җибәрелгән

вә росөлиһи — вә инандым Аллаһы тәгәләнең барча расүлләренә (Кор'әндә 27 расүл кергән)

вәл йәүмил әхыйри — вә инандым кыямәт көненең булуына, ул кыяметтә булачак барча хөкемнәргә

вәлкадәри хайриһии — вә инандым Аллаһы тәгәләнең тәкдирләренә, ул тәкдирнең яхшысына

вә шәрриһии минәллааһи тәгәлә вә ул тәкдирнең яманы Аллаһы тәгаләдән булуына

вәл бәгси бәгдәлмәүт — Вә инандым үлгәннән соң терелмәккә

# ТӨРЛЕ ДОГАЛАР

## Намазга кушыла торган догалар

## ФӘЛӘКНЕҢ МӘГНӘСЕ

Коль әгүдө бираббил фәләкой мин шәрримәә халәко. Вә мин шәрри гаасикойн изәә вәкабө. Вә мин шәрриннәффәәсәәти фил гөкадө. Вә мин шәрри хәәсидин изә хәсәдө.

Мәгнәсе: Әйт и, Мөхәммәд (Мостафа салләллаһу гәләйһи вәсәлләм)! Сыгынамын мин таңны тудыручы раббыма дип.

Аның һәрбер яраткан нәрсәләренең зарарыннан сыгынамын (усал ерткычлардан, зарарлы гөмбә вә үләннәрдән).

Һәмдә караңгы кичәнең караңгылыгыннан, кайчан караңгылыгы һәрбер нәрсәне капласа.

Һәмдә төеннәргә сихыр теләп өрүче хатыннарның явызлыгыннан сыгынамын.

Һәмдә көнче кешенең көнчелегеннән Аллаһы тәгаләгә сыгынамын.

Әмин

### Нәснең мәгнәсе

Коль әгүдө бираббиннәәси, мәликиннәәси, иләәһиннәәс. Мин шәррил вәсвәәсил ханнәәс. Әләзии йөвәсвисө фии содуриннәәси. Минәл җиннәти вәннәәс.

Әйт син и, Мөхәммәд (Мостафа салләллаһу гәләйһи вәсәлләм)! Сыгынамын мин әдәмнәрнең Раббысына дип.

Әдәмнәрнең падишасына, ягъни, Аллаһы тәгаләгә.

Әдәмнәрнең тәңресенә

вәс-вәсә кылучы ханнәснең (шәйтанның шәреннән)

шундаен вәс-вәсә кылучы ки,

вәс-вәсә кылыр ул әдәмләрнең күкрәкләренә

җеннәрдән һәм әдәмләрдән булучылардыр.

**Бер кешенең үлгән хәбәрен ишеткәндә, берәр кайгы яки шатлык килгәндә ошбу дога укылыр:**

Иннәә лилләәһи вә иннәә иләйһи раажигон

Мәгнәсе: Без һәркайсыбыз Аллаһы тәгаләнекедер вә һәркайсыбыз Аллаһы тәгаләгә кайтачакларбыз.

**Ашап-эчеп бетергәч укыла торган дога:**

Әлхәмдөлилләәһи раббил гәәләмиин. Әлхәмдөлилләәһиллэзии. Этогәмәнәә, вәсәкаанәә, вәҗәгәләнәә минәл мөслимиин.

Мәгнәсе: Әлхәмдөлилләһ, Аллаһы тәгалә безне туйдырды вә эчертте, вә дәхи безне мөселманнардан кылды.

**Берәр урынга утыргач кыла торган дога:**

Аллааһөммә энзилнии мөнзәлән мөбәәракәү үә энтә хайрол мөнзилин

Мәгнәсе: Я, Раббем! Мине мөбәрак җиргә индергел. Син хәерле индерүчесең.

## МӘЕТ КҮМҮ ТӘРТИБЕ.

Үләргә яткан хастаның хәлен белергә барганда авыру янында, кәефенә карап, күп утырырга ярамый.

Авыруы көчле булган әдәмгә «Иман кәлимәсе китер» дип көчләргә ярамый, үзең, авыру ишетерлек итеп, шәһәдәт кәлимәсен кычкырып әйт, ягни Лә иләһә илләллаһө дип тәһлил әйтелер.

Әҗәле якынлашканда авыруны уң ягына яткырырга тырыш.

Үләсе кеше янында ясин шәрифне вә башка догаларны кычкырып укырга кирәк.

Кеше үлгәч кыйблага аякларын борып куеп, аяк-кулларын сузып куй. Күзләрен йомдырып, авызын ябып, иягеннән, авызы ачылмасын өчен, бер яулык белән бәйләп куй, башына яулык бөркәт (хатын-кыз булса). Күкрәге кабармасын өчен бер кайчы кебек тимер нәрсә куясың.

### Кәфен кисү тәртибе.

Кәфен кискәндә тәһәратле булу кирәк. Кәфен ирләргә 3 кат, хатыннарга 5 кат исәбеннән киселә.

Беренче кат кәфен киселә мәетнең башыннан да, аягыннан да 30 см озынрак итеп алына вә икенче катында шулай ук башыннан вә аягыннан 30 см озын итеп алына.

Киңлеге мәетнең йуанлыгына карап! йуанлыгыннан әйләндереп үлчәсәк 2 кат, өстенә куеп үлчәсәк 4 мәртәбә исәбеннән алына.

Әхыйрат күлмәге мәетнең җилкәсеннән алып, аяк йөзләрен капларлык итеп киселә.

Бөркәнчек (яулык) башыннан кендегенә кадәр алына.

Хирка (бил-бау) мәетнең йуанлыгыннан үлчәсәң 2 кат, өстенә куеп үлчәсәң 4 мәртәбә исәбеннән алына, хирканың киңлеге ярты иң.

Әхыйрат күлмәгенә материал урталай бөкләнгән хәлдә алына, ягни: бер кат материалны мәетнең җилкәсеннән алып аяк йөзләрен капларлык итеп үлчисең дә, яңадан шуның кадәр аласың, бөкләгән урыннан баш тыгарлык итеп кисәсең.

### Мәетне йуу тәртибе.

Асыл йуучы мәетнең сул ягында булыр (сул кул белән астын чистарту өчен, истинҗа алдыру өчен).

Мәетне йуа торган су кан җылысы кебек булсын.

Мәетне йуганда су йөртү өйнең уңаена карап (ишек торышына карап).

Әүүәл өч кисәк чүпрәк әзерләп куясың — эчке тәһәратен алдыру өчен.

Алты кисәк чүпрәк әзерлисең — авызын, борынын чистарту өчен.

Мәетне колашага күтәреп салабыз, чүпрәге яки күлмәге белән. Мәетнең күлмәген аяк очыннан югарыга таба, җиңен беләзектән югарыга таба кисәбез.

Күлмәген кисми салгызып алсаң да ярый.

Гәүрәтен каплап куябыз.

## Мәетне йуарга әзерләгәндә

Әүүәл әзерләгән 3 кисәк чүпрәк илә эчке тәһәратен алдырабыз.

Бөтен тәненә йомшарту өчен марляга сабын ышкып, күбек белән чылатабыз. Чәчен сүтеп, башын сабынлап юабыз, алгы ягын сабын күбеген бетерү өчен кабат йуабыз.

Алгы ягы йуылып бетте.

Әүүәл сул кабыргасына яткырып, уң ягын аркалары белән, сабынлап йуабыз. Колашаны йуып мәетне салабыз. Мәетне уң кабыргасына яткырып, сул ягын аркалары белән йуабыз да, колашаны пакләп мәетне салабыз.

Мәетнең эчке тәһәратен алдырганчы, мәетнең әзрәк җилкәсен күтәреп, эченә, (корсагына) экренләп басып куябыз, нәҗесләре чыксын өчен.

Хәзер камил тәһәратен алдырабыз:

Уң кулын, сул кулын йуабыз.

Өч чүпрәк белән авызын йуабыз.

Өч чүпрәк белән борынын йуабыз.

Өч тапкыр йөзен йуабыз.

Өч тапкыр уң беләгенә, аннан сул беләгенә терсәкләре белән су коябыз.

Үзебезгә ничек мәсих кылсак, мәеткә дә шулай мәсих кылдырабыз.

## Әзер мәетне гөсел коендыру.

Гөсел коендырганда: «Илаһи! Ният кылдым әхыйрат гөселен коендырмакка, тәннәрен пакләмәккә, Әшһәд әл лә

иләәһә илләллааһө вә әшһәдө әннәә Мөхәммәдән гәбдөһү вә расулүһү» дип әйтелә.

Мәетнең башын бераз күтәргән хәлдә башыннан су коябыз, баш турысыннан колашаны йуып җибәрү кирәк.

Уң як җилкәсеннән ботына кадәр, сул як җилкәсеннән ботына кадәр су коябыз.

Сул ягына яткырып, уң як җилкәсеннән аркаларын гөселләндерәбез һәм колашаны йуып җибәрәбез.

Уң ягына яткырып, сул як җилкәсеннән аркалары белән гөселләндерәбез дә, колашаны паклап мәетне салабыз.

Уң аягын һәм сул аягын, бармак араларын аралап, гөселләндерәбез.

Чәчләрен ике якка сузып салабыз.

Нәжесе чыгудан шикле булса мамыкны марляга төреп, бөят (пробка) куябыз.

Кабат нәжесе чыккан булса гөсел кабат кайтарылмый, шул урынны гына паклибез һәм мамык белән бөкелибез. Мамыкны марляга төреп, бөят куеп, ботын бәйләп куябыз. Чиста тәненә корыткычны явып куябыз, йуу тәмам.

Мәетне әзерләп куелган кәфен өстенә күтәреп салганда, уңай булсын өчен, бил турысына бер метр ярым марля куябыз. Бер кеше шул марлядан тота, бер кеше башыннан, бер кеше аягыннан тотып мәетне әзер кәфен өстенә салабыз.

### Мәетне төрү тәртибе.

Чиста урын өстенә кыеклап әүвәл юрган яки одеял җәябез, юрганга берәр тап төшмәсен өчен полиэтилен (клеенка) җәябез.

Гүргә индерү өчен 2,5 м озынлыкта 3 сөлгене төрелгән хәлдә куябыз.

Хирканы (билбау) бил турысына куябыз, хирканың киңлеге ярты иң.

Кәфеннең ике катын да җәябез. Аннары яулык куябыз. Болар өстенә әхыйрат күлмәге куябыз.

Аннары мәетне әзер кәфен өстенә салабыз, чәчен буе белән күкрәк өстенә саласың.

Әхыйрат күлмәген тулысынча кәфен өстенә куеп, бер катын бөкли-бөкли баш очына кадәр күтәреп куябыз да, мәетне салгач күлмәкне башын чыгарып өстенә төшерәбез.

Авызы ачылмасын өчен иягеннән башына кадәр авызын бәйләп куябыз һәм яулыгын беркетәбез.

Беренче кат кәфеннең әүүәл сул ягын ябабыз, битләре дә ябыла. Аннары уң ягын ябабыз.

Икенче кат кәфеннең сул ягын вә уң ягын ябабыз.

Аннары хирканы ябабыз да, аягы очындагы кәфенен бәйлибез. Әзерләнгән сөлгеләрне мәет өстенә куябыз һәм юрганы белән төрәбез, алып барганда таралмасын өчен аяк ягын бәйләргә кирәк. Мәетне өйдән алып чыкканда аягы алдан чыга.

Алып барганда башы алда була.

Мәетне мөмкин кадәр ашыктыру хәерле, чөнки инде ул җир кешесе, үз урынына ашыктыру яхшы.

## ҖЕНАЗА

Йуып-кәфенләнгән мәет башы Мәгриб тарафина (кояш батышы) куелган хәлдә җиргә куелыр. Соңыннан имам мәетнең күкрәге турысына, җәмәгәт имам артында саф-саф булып тезелгәч, җеназа намазы укыла. Намаз укучы бер генә кеше булса да мәетнең күкрәге турысында булмак тиешдер.

Җеназа намазының шартлары башка намаз укыгандагы шартлардыр, ләкин җеназа намазына билгеләнгән бер вакыт юктыр, дәхи җеназа намазы өчен мәетнең йуылган булуы шарттыр.

Җеназа намазының кыйраәте рокугы һәм сәҗдә кәгдәләре юк. Дүрт тәкбир, ике сәләм илә тәмам кыйлынадыр.

### Җеназа намазын уку рәвеше

Җеназа намазы бу рәвешчә укыла:

«Иләһи! Ният кылдым җеназа намазы укымакка, Аллаһы тәгаләгә сәнә өчен. Пигәмбәребезгә салават өчен. Бу мәеткә дога вә савабы өчен, Халисан лилләәһи тәгәлә, Аллаһө экбәр дигәч тәкбир илә намазга керешерләр. Кулларын баглаган хәлдә СӘНӘ догасы укылыр (сөбөхәнәкә ...). Моннан соң кулларын күтәрмичә генә янә бер тәкбир әйтелер (Аллаһө экбәр), монысы икенче тәкбир буладыр. Имам булган кеше бу тәкбирләрне кычкырып әйтер. Икенче тәкбирдән соң салават шәрифе укылыр (эттәхиййәтнең икенче яртысы), сонра икенче тәкбир кеби өченче тәкбир әйтелер. Өченче тәкбирдән соң җеназа догасын укыгач, дүртенче тәкбирен дә әүүәлгеләре кеби әйтеп, һәр ике тарафка Әссәләмө гәләйкөм вә Рахмәтуллааһ

дин сәләм бирелер. Уң тарафка сәләм биргәндә уң кул, сул тарафка сәләм биргәндә сул кул җибәрелеп намаз тәмам булыр.

## ҖЕНАЗА ДОГАЛАРЫ

Мәeuткә өченче тәкбирдән соң ошбу дога укылыр:

Аллааһөммә әгфир ли хәййинәә вә мәййитинәә вә шәәһидинәә вә гааааибинә вә саагиринәә вә кәәбиринәә вә зәкәринәә вә өнсәнә. Аллааһөммә мән әхйәйтәһү миннәә фә әхиһи гәләл исләәми вә мән тәүәффәйтәһү миннә фә тәүәффәһү гәләл иимәән (Вә хусса һәзәл мәййитә бирраухи вәррахәти вәррахмәти вәл мәгфирати вәрридвән). Аллааһөммә ин кәәнә һәәзәл мәйтө мөхсиинән фәзид фии ихсәәниһи вә ин кәәнә мүсиән вәтәҗәвәз гәнһө (вәләккыйһил әмнә вәл бушра вәлкәрамәтә вәззөлфи, Бирахмәтикә йә әрхәмәррахимин).

Шул рәвешчә җеназа намазын уку мөселман булган һәрбер мәет өчен фарыздыр. Кирәк ир, кирәк хатын, вә кирәк сабый бала булсын, әгәр җеназа намазы укылмый күмелсә, ул вакыт кәберенә укылыр.

Бер бала анадан терек хәленчә тугач та үлсә, аңа да җеназа намазы укыла һәм исем биреләдер. Әмма анадан туганда ук үлек булса исем бирелеп, йуылып, кәфенләп дәфен ителер.

### Мәетне кәбергә дәфен кыйлу.

Кәбер кыйблага аркылы, ягни бер башын кояш чыгышына вә бер башын кояш батышына кыйлыб, мәетнең буена күрә казылыр. Кыйбла тарафыннан ләхет ачылыр, шул ләхеткә мәет уң тарафы илә, йөзе кыйблага, аяклары кояш чыгышына, башы кояш батышына булганы хәлдә яткырылыр, моннан соң ләхет өч кирпич илә, яисә агач вә камыш кеби нәрсә белән булса да капланып, туфрак белән күмелер.

**Мәетне ләхеткә куйгач** ошбу дога укыла:

Бисмилләәһи вәдагнәкә (хатын-кыз булса — ВӘДАГНӘКИ) вәгәлә милләти Расулүллаһи сәлләмнәк.

Мәгнәсе: Без сине Аллаһының исеме белән куйдык, пәйгәмбәребезнең өммәтеннән санадык.

**Кәбергә туфрак салганда** ошбу дога укылыр:

МИНҺӘӘ ХАЛӘКНӘӘКӨМ ВӘ ФИИҺӘӘ НӨГИИДӨКӨМ

ВӘ МИНҺӘӘ НӨХРИЖӨКӨМ ТӘРАТӘН ОХРА.

Мәгнәсе: Без (Аллаһы тәгалә әйтә) сезне шушы туфрактан яраттык, шуңа кайтарып кергезәбез, яңадан шуңардан кубарып (терелтеп) чыгарабыз.

Соңыннан мәетнең рухына Кор'ән укып таралырлар.

## КОРБАН

Мөселман кешеләргә һәр елны, корбан чалына торган көннәрнең берсендә, үзе өчен корбан чалмак вәҗептер.

Корбан чалына торган көннәр: Гәет намазыннан соң башлап, уникенче Зөлхиҗәнең ахшам вакытына кадәр булган мидәттер (вакыттыр).

Ошбу мидәт эчендә корбан бугазлый алмаган кеше, әгәр корбанлыгы алынмаган булса, корбанлыкның киммәтен (бәһәсен) сәдака кыйлу вәҗеп буладыр, әгәр корбанлыгы алынган булса, ул вакыт корбанлыкнын үзен садәка кыйлу тиештер.

Мөсафир кешегә дәүләте булса да корбан чалу тиеш булмас.

Корбанлыкның итен яисә тиресен сату дөрес түгелдер. Бай кешеләр тиресен һәм корбан итенең өчтән бер өлешен садәка кыйлу тиештер һәм зур саваплы булу гәмәлдер. Мохтаҗ кемсә һич бер нәрсәне садәка кыйлмыйча үз файдасына гына тотса да дөрес булыр. Тиресеннән күн эшләтсә яисә кор'әи кеби файдалы нәрсәләргә алмаштырса да дөрестер. Әмма сатып, акчасын башка урынларга тоту дөрес булмас.

### Корбанга лаек хәйваннар.

Куй, кәҗә, сарык, дөя, сыер корбанга лаек хәйваннардыр, әммә ат һәм каз, үрдәк, күркә кеби кошлар корбанга яраклы хәйваннар түгелдер.

Сукыр хәйваннарны, аксак, тешсез һәм колаксыз хәйваннарны корбанга чалу дөрес түгелдер.

Өшәнгән, җелеге кибәрлек дәрәҗәдә ябык хәйван, мөгезе яисә койрыгы төбеннән үз өзелгән хәйваннар корбанга дөрес түгелдер.

## Корбанлыкның яше.

Кәҗә, сарык, куйга бер яшь, сыерга ике яшь, дөягә биш яшь тулган булу шарттыр, ким булганда дөрес түгелдер.

Әгәр куй белән сарык бик зур һәм симез булып, бер яшь тулган сарык һәм куйлардан аермасыз булсалар, алты айлык та дөрес булыр, әммә кәҗәгә шиксез бер яшь тулган булу шарттыр.

Куй, сарык вә кәҗә берәр кеше өчен генә корбан кыйлынырлар, сыер вә дөя җидешәр кеше өчен корбан кыйлынсалар да дөрес булыр. Бер кеше бер үзенә генә бер сыер я бер дөя корбан кыйлса да дөрес вә олугы савaплы булыр.

## Корбанга кагылышлы башка мәсьәләләр.

Беренче мәсьәлә: бер кеше корбанлык алгач ул корбанлык балаласа, баласы терек хәленчә садәка кыйлыныр, янсә энкәсе белән бугазланыр, ите садәка кыйлыныр, янсә балалаган хәйван калып, аның урынына икенче хәйван бугазланса да вәҗеб булыр, әгәр икенчене алырлык бай булмаса шул да ярый.

Корбан бугазлаганда укый торган дога:

БИСМИЛЛӘӘҺИРРАХМӘӘНИРРАХИИМ

Аллааһөммә һәәзәә минкә вә иләйкә иннәә саләәтии вә нөсөкии вәмәхяйә вәмәмәәтии лилләәһи раббил гәәләминнә ләә шәриикә ләһө, вәбизәәликә өмиртө вәәнә әүвәлөл мөслиминә, аллааһөммә тәкаббәл миннә һәәзиһил әдхиййәйтә (кем өчен корбан чалуыңны әйт), бисмилләәһи Аллааһө әкбәр (тиз әйтергә) дип бугазлыйсың вә бу сүзләрне әйтәсең: «Я, Раббем! Бу корбанлыгымны мин бәндәңнән кабул кыйлгыл, нитәки кем Ибөраһиим Хәлилеңнән кабул кыйлдың» вә янә күңелеңнән моны әйтергә кирәк: «Әй, Бари Ходая! Әгәр әмерең булса иде, синең ризалыгың өчен үземне корбан кыйлыр идем»,— дип.

Бугазлаганнан соң дөнья сүзен сөйләмәстән тиз генә ике рикәгәт намаз укыла, һәр рикәгаттә берәр Әлхәм, унар мәртәбә Ихлас (Кольһүаллаһ) сүрәсен укып, һәр рикәгаттә сәҗдәдә:

Сөбөхәәнәллааһи халикыйн нури сөбөхәәнә мән һүә каимен, гәлә көлли нәфсин бимә кәсәбәт.

## БАЛАГА ИСЕМ КУШУ

Азан әйтеп азан догасын укырга. Аннары камәт төшерәсең дә баланың ике як колагына фәлән углы яки фәлән кызы дип исем кушасың.

Аннан соң бу дога укыла:

Аллааһөммә әҗгәлөһө фил исләми нәбәтән хәсәнәү вәҗгәлөһө мәсгүдән фиддөньйә вәл әхыйра.

Мәгнәсе: Я, Раббем! Бу бала ислам динен куәтләүче, ата-анасына игелекле, миһербан-шәфкәтле, тәүфиклы зөррият (бала) булсын иде, ата-аналарына тигезлек, саулык, сәләмәтлек белән үстерергә насыйп итсәң иде.

Әмин

## НИКАХ

Никах укыр алдыннан башта кыздан сорарга:
Син фәлән кызы фәлән! Фәлән углы фәләнгә хәләл җефетлеккә риза булып бардыңмы? — дип.

Егеттән сорарга:
Син фәлән углы фәлән! Фәлән кызы фәләнне хәләл җефетлеккә кабул итеп алдыңмы?

Монн[illegible] соң ошбу дога укылыр:

БИСМИЛЛӘӘҺИРРАХМӘӘНИРРАХИИМ

Әлхә[illegible] лилләәһилләзии мөйәссирил өмүүри вә мөкаддиришшөһүри вә мөгаййирил әзминәти вәддөһүр. Әлләзии нәәҗәә Мүүсәә мәгәһүү гәләттур. Вә әнзәләттәүратә вәл Инҗиилә вәл фөркаанә вәззәбүр. Вә әхәләнникәхә мәкрүүнән бишшөһүүди вәл мөһүүр. Кәмә каалэллааһө сөбөхәнәәһү вә тәгәәләә фии сүүратиннүр.
Вә әнкихәл әййәәмә минкөм вәссаалихинә мин гибәәдикөм вә иимәәәъикөм. Ин йәкүүнүү фөкарааааъә йөгниһимуллаһө мин фәдлиһ.

Ләкад җәәәәъәл әхбәәро гәнин нәбиййи салләллааһө гәләйһи вәсәлләм. Әнникәхө сөннәти фәмән рагибә гән сөннәти фә ләйсә миннии. Әннәәкихө раагибөн вәл мәнкүхәтө мәргүбәтөн вәл мәһро гәләә мәә тәрадайә.

Тәнәәкәхү тәвәәләдүү, тәкәәсәру фә иннии өбәәһии бикө мөл өмәмә йәүмәл койәмәһ.

Әсбәталлааһө фии содурил җәәнибәйни хәббәтәл мәхәббәһ,

Әсбәталлааһө фии содурил җәәнибәйни хәббәтәл мәхәббәһ.

Әсбәталлааһө фии содурил җәәнибәйни хәббәтәл мәхәббәһ.

Вә әкулө каули һәәзәә вә әстәгфируллааһәл гаффәәрали вәләкөм вә ли сәәәәъирил җәмәәгәтил мөслиминә әҗмәгин.

Һәәзәә хөкмөн мин әхкәәмил хәкиминә вә раббил гәләминә вә сөннәтөн мин сөнәнил әнбияги вәл мөрсәлин.

Никахның мәгнәсе:

**Замана вә дәверләрне алмаштырып торучы, айларны тәкдир кылучы, эшләрне җиңел кылучы Аллаһыга мактау вә шөкерләребез булсын.**

Шундаен ки Аллаһы ул, Муса гәләйһиссәлләм аның белән Тур тавында мөнәҗәт кылышты һәм ул Аллаһы Тәүрат, Инҗил, Забур һәм Кор'әнне иңдерүчедер һәм никахны хәләл кылды, мәһәр һәм шаһитларның хәзер булуы белән бәйләп. Нитәки Аллаһы тәгалә НУР сүрәсендә әйтте: «Сез никахландырыгыз үз кул астыгызда булган колларны һәм кәнизәкләрегезне. Гәрчә алар фәкир булсалар да шушы никах сәбәпле Аллаһы аларны олугы фазлыннан олы нигмәтләр белән нигмәтләндерер». Тәхкыйк, пәйгәмбәребездән хәбәр килде (булды): «Никах минем сөннәтемдер. Сөннәтемнән баш тартучы минем өммәтемнән түгел». Никахлаучы (ир җенесе) эшне башлап кузгатучы, никахланучы шул эшне риза булып кабул итүче. Мәһәрне ике арада риза булышу белән килешә.

«Өйләнешегез, балалар тудырыгыз, күбәегез ди пәйгәмбәребез,— мин кыямәт көнендә сезнең күплегегез белән башка өммәтләр алдында мактанырмын» (балаларыгызны үтермәгез).

Никах укыганда 3 мәртәбә кабатланган ӘСБӘТАЛЛААҺӨ ФИИ СОДУРИЛ ҖӘӘНИБӘЙНИ ХӘББӘТӘЛ МӘХӘББӘҺ дигән сүзнең мәгнәсе:

Аллаһы тәгалә шушы ике парга (җәни бәйни) күкрәкләренә өлфәт мәхәббәт беркетсә (салса) иде.

Аннан соң ошбу теләкне теләргә:

Я, Раббем! Бу яшьләргә Әдам гәләйһиссәләм белән Һава разиаллаһы гәнһөмәләр мәхәббәтен бир.

Я, Раббем! Бу яшьләргә Ибраһим гәләйһиссәләм белән Сара разиаллаһы гәнһөмәләр мәхәббәтен бир.

Я, Раббем! Бу яшьләргә Мөхәммәд Мостафа сәлләлла-һу гәләйһи вәсәлләм белән Хәдичә разиаллаһы гәнһеләрнең мәхәббәтен бир.

Я, Раббем! Бу яшьләрнең араларына өлфәт мәхәббәт бирел, никахлары төзек булса иде.

Ата-аналарына миһербан-шәфкәтле, тәүфиклы балалар булсалар иде. Болардан туачак балалар да изге балалар булып, ислам динен куәтләүче, үзләренә догачы, бәхетле балалар булып, тигезлек, саулык, сәламәтлек белән үстерергә насыйп итсәң иде.

Әмин

4 рикәгәтле сөннәт намазларында Әлхәм укыганнан соң укыла торган догалар:

БИСМИЛЛӘӘҺИРРАХМӘӘНИРРАХИИМ

Аерым укыганда һәрбер сүрә алдыннан бисмиллә әйтелсә дә, намаз эчендә ниятләгәннән соң бисмиллә Әлхәм алдыннан гына әйтелә, башка сүрәләр алдыннан бисмиллә әйтелми.

Коль әгүдө бираббил фәләкый мин шәрримәә халәко. Вә мин шәрри гаасикыйн идәә вәкабө. Вә мин шәрриннәффәсәәти фил гөкадө. Вә мин шәрри хәәсидин идә хәсәө.

## ШӘРИГӘТ ТӘРТИПЛӘРЕ

Беренче сәләм биргән кешегә (Әссәләмө гәләйкөм дип), «Вәгәләйкөм әссәләм» дип җавап бирмәк тиеш булыр, беренчә кеше булганда арадан берсе сәләм кайтарса җитәдер, һәр каюсының кычкырып сәләм алуы тиеш түгелдер.

Бер кеше төчкергәч «Әлхәмдөлиләәһии» дип әйтсә (төчкергәч шулай дип әйтү тиеш), аның янында торган кешегә «йәрхәмөкаллааһө» дип җавап бирергә тиеш, бу да сәләм кайтару кебидер.

Аллаһы тәгәләнең исемен әйткәндә Аллаһ дип кенә түгел, Аллаһы тәгәлә дип сөйләү тиеш.

Бер эшне эшләргә ниятләгәндә Иншә Аллаһ дип әйтергә кирәк.

Пәйгәмбәребез салләллаһу гәләйһи вәсәлләмнең исем шәрифләре зекер ителгәндә, ягни берәр кемсә пәйгәмбәребезне исеме белән генә Мөхәммәд дип әйтсә, ишетүчегә салләллаһу гәләйһи вәсәлләм дип салават өстәп кую тиештер. Күп кеше җыелып торганда әйтелсә бер кеше өстәү җитәдер.

Гөнаһ эшне эшләмәсәләр барча мөселман кәрдәшләр белән һичбер вакытта үпкәләшмичә, тату тормак тиеш.

Бу китапта бар догалар да Тәҗвид кагидәсе белән биреләдер.